ИГЕНЧЕЛӘР БӘЙРӘМЕ
Һөнәргә тугрыларны хөрмәтләделәр
> 2

БЕР АВЫЛГА – БЕР СЫЕР
Без нинди сөт эчәбез?
> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ
«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары
> 7

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус кушымта
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 147 (28729) | Шимбә | 9 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ПРЕЗИДЕНТ ЮЛЛАМАСЫ:

УҢЫШ АДЫМНАРЫ

Кичә Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык Юлламасы белән мөрәҗәгать итте. Президентның шул рәвешле 11 нче тапкыр чыгыш ясавы бу.

Төгәл, саллы һәм кешеләр турында. Президент Юлламасын соңыннан без сорашкан кешеләр шулай дип бәяләде. Бер сәгать дәвам иткән Юлламада республиканың барлык тармакларында башкарасы эшләр барланды, максат-бурычлар билгеләнде. Шул ук вакытта халыкны борчыган күп кенә сорауларга җавап та алынды. Гомумән, еллык Юлламаның буеннан-буена Рөстәм Миңнеханов Татарстанның уңыш нигезе аның тырыш халкында икәнлеген ассызыклады. Кайсы гына тармак турында сүз башласа да, шушы өлкәдә фидакарьләрчә хезмәт куйган, аның үсешенә саллы өлеш керткән кешеләргә рәхмәт сүзләре җиткерде ул. Залда утырган хезмәтчәннәрне, табибларны, алдынгы укучыларны, үрнәк гаиләләрне күтәреп, аерым рәхмәтләрен әйтте Президент. Хөкүмәт алдында торган иң төп максат-бурыч дип тә халыкның яшәү дәрәҗәсен яхшыртуны атады ул.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның шәһәр мохитен үстерү юнәлешендә алып барган тәҗрибәсен Россиядә аналоглары булмаган үрнәк дип атады. Халык тарафыннан аеруча җылы кабул ителгән «Безнең ишегалды» программасының киләчәктә дә тормышка ашырылачагын искәртте. Булдыру гына түгел, булганның кадерен белергә дә кирәк, билгеле. Бу урында Рөстәм Миңнеханов төзекләндерелгән мәйданчыкларны тәртиптә тота белмәүчеләрне дә шелтәләп алды. «Бу яктан Чаллы шәһәрендә, Бөгелмә, Лаеш, Кукмара, Менделеевск һәм Балык Бистәсе районнарында кимчелекләр бар. Район җитәкчелеге, җирле халыктан яңа төзекләндерелгән ял урыннарына сакчыл карауларын көтәбез», – диде Президент.

Мәктәпләрне саклауга аеруча зур игътибар биреләчәк. «Казан һәм Пермьдәге фаҗигале вакыйгалар һәр ата-ананың йөрәгенә борчу салды. Безнең тарафтан мәктәп биналарының физик сакланышына өстәмә акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. Моннан тыш республика җитәкчесе укытучы һәм укучылардан килгән сигналларны игътибарсыз калдырмыйча, аларны тиз арада күтәреп алырга, яшүсмерләр арасында җинаятьчелек очракларын кисәтү белән актив шөгыльләнергә кирәклеген дә искәртте.

Куркынычсызлык димәктән, Рөстәм Миңнеханов сәнәгать комплексы алдында торган мөһим бурычлар турында сөйләгәндә дә шул мәсьәләгә тукталды. «Соңгы елларда Татарстанның сәнәгать объектларында җәмәгатьчелектә көчле яңгыраш алган берничә вакыйга булды. Алар өчен оешма җитәкчеләре шәхсән җаваплы», – дип искәртте Президент. Бу – Президент сәнәгать тармагы каршында куйган бурычларның берсе генә.

Татарстан Президентының еллык Юлламасында гаиләләргә кагылышлы яңалык яңгырады. Республикада «Ата-ана фидакарьлеге» дип исемләнгән яңа дәүләт бүләге гамәлгә кертеләчәк. «Россия Президенты Владимир Путинның күптән түгел чыккан Указы нигезендә, Әтиләр көне гамәлгә кертелде. Ул халык тарафыннан уңай кабул ителде. Моңа өстәмә итеп, Татарстанда гаилә абруен, ата-аналар хезмәтенең дәрәҗәсен арттыру максатыннан яңа дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медален гамәлгә кую турында карар кабул ителде», – дип хәбәр итте Президент.

Рөстәм Миңнеханов еллык Юлламасында коронавируслы тормышыбызны да читләп үтмәде. «Ни кызганыч, пандемия тәмамланмады. Вирус куркыныч тудыруын дәвам итә. Мондый шартларда коллектив иммунитет бик мөһим роль уйный. Аңа вакцина ясату хисабына гына ирешеп була. Пандемиягә каршы көрәшнең бердәнбер юлы бу», – дип искәртте республика җитәкчесе.

Юлламада яңгыраган тагын бер яңалык: 2022 ел Татарстанда «Цифрлаштыру елы» дип игълан ителде. Цифрлаштыруны Президент, беренче чиратта, халыкның тормыш сыйфатын яхшырту, аларның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү һәм керемнәрне арттыру, шулай ук бизнесның конкуренциягә сәләтен арттыру мөмкинлеге бирә торган инструмент дип атады. «Алга таба «цифр»га күчү өчен безгә принципиаль рәвештә яңа катлаулы мәсьәләләргә алынырга кирәк», – диде ул.

Президент чыгышын халык мәкале белән тәмамлады: адым-адым юл булыр, тамчы-тамчы күл булыр. Юллама да уңышка илтүче адымнарны барлауга багышланган иде бит.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Юллама тексты тулысынча 3-6 битләрдә >

Юлларда тәртип кирәк

Россия Президенты Владимир Путин кешеләрнең юл-транспорт һәлакәтендә күпләп үлүләренә бәйле борчылуын белдерде. Хөкүмәт полиция һәм юл хезмәтләре куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен барысын да эшләргә тиеш. Вице-премьер Марат Хөснуллин белән очрашу вакытында Россия Президенты шундый күрсәтмә бирде. «Хәрби хәрәкәтләрдә югалткан кебек, юлларда да кешеләрне шулай югалта алмыйбыз. Мин күргәннәрнең барысы да – комплекслы эш. Эчке эшләр министрлыгының да, юл хезмәтләренең дә бу җәһәттән эше яхшырды. Санитар авиацияне үстерү кирәк, авариядән соң беренче сәгатьтә үк кешегә ярдәм күрсәтер өчен мөһим бу», – диде Владимир Путин.

Искәртеп үтик: эчке эшләр министры Владимир Колокольцев, соңгы ун елда аварияләр нәтиҗәсендә 220 мең россияле вафат булган, 2 миллионнан артыгы төрле җәрәхәтләр алган, дип белдергән иде. 2030 елга юллардагы үлем-җитемнәр санын киметү максаты тора.

25тән дә арттырмаска

Ил хөкүмәте, төзелеш материалларына бәя арту сәбәпле, капиталь төзекләндерүгә бәя күтәрүне хуплады. Тик аны 25 проценттан арттыру рөхсәт ителми. Бу хакта карарны Россия Премьер-министры Михаил Мишустин раслады.

Шулай ук хезмәт күрсәтү бәясе төбәк операторының ел саен капиталь ремонт программасын финанслау өчен тотарга хокукы булган акча күләменнән артып китә алмый.

Карар нигезендә, бәяләрне арттыру турында өстәмә килешү төзелеш материалларына чыгымнарны арттыруны раслаган дөрес смета булганда гына төзелергә мөмкин.

850 кубометр чүп җыйганнар

«Татарстанның чиста урманнары» акциясендә катнашучылар урман территорияләреннән 850 кубометр чүп җыйган. Бу хакта Татарстанның Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итә.

Урманнарны чүп-чардан чистартуда министрлык карамагында булган оешма белгечләре, башка предприятиеләр хезмәткәрләре, урман кишәрлекләрен арендалаучылар, бакчачылык ширкәте, кооператив вәкилләре, студентлар һәм волонтерлар катнашкан.

Урман хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләре 24 чишмәне төзекләндергән, 66 мәгълүмат тактасы, 59 ял урынын рәткә китергән. 2 мең кубометр коры куак һәм ауган агачларны бергә туплаганнар.

Исегезгә төшерәбез: «Татарстанның чиста урманнары» акциясенең көзге этабы 13 сентябрьдә башланган иде. Ул 13 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

tatarstan.ru

4 көн ял көтелә

Ноябрь аенда Россия халкын кыска эш атнасы көтә. Билгеле булганча, 4 ноябрьдә Халыклар бердәмлеге көне бәйрәм ителә. Ул быел пәнҗешәмбегә туры килә. Исегездә булса, 2 гыйнвардагы ял 5 ноябрьгә күчерелгән иде. Шулай итеп, Россия халкы 4, 5, 6, 7 ноябрьдә ял итәчәк.

Суытачак та, җылытачак та

Синоптиклар быелгы кышның нинди булачагы турында фаразлар китерде. Гидрометеорология үзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд белдергәнчә, быел ул бик еш кына җылы һава торышы белән дә куандырачак, кискен салкыннар да алып киләчәк. «Росгидромет мәгълүматлары буенча, температураның сизелерлек һәм көчле түбәнәюе көтелә, әмма бу кышта еш җылытачак та», – дип фаразлый ул. Россиянең Европа өлешендәге күпчелек төбәкләрдә һава температурасы норма чикләрендә яисә бераз югары булачак икән.

Яңалык

Дүшәмбедән чикләнәбез

Коронавируска бәйле вазгыять кискенәю сәбәпле, 11 октябрьдән Татарстан яңа кагыйдәләр буенча яши башлаячак. Татарстан Хөкүмәте чир таралуны киметү өчен өстәмә чикләү чараларын кабул итте.

➤Театр, кинотеатр, цирк, концерт залларында, спорт, мәдәният, күңел ачу чараларында халык саны 50 проценттан артмаска яисә 500 кешедән дә күбрәк булмаска тиеш. Аерым шартлар үтәлгәндә генә заллар 70 процентка тулы булырга мөмкин. Бу шартларга барлык хезмәткәрләрнең һәм оештыручыларның вакцина ясаткан булуы, коронавирус белән чирләгәнлеге хакында яисә вакцина ясатырга ярамаганлыгы турында белешмәләрнең берсен күрсәтүе керә. Оештыручыларга чараны бер атна алдан Татарстанның оператив штабы белән килештерергә кирәк. Спорт, күңел ачу, мәдәни чаралар турында исә 30 көн алдан кисәтергә кирәк.

➤Кунакханәләр 50 процентка гына тулы булырга тиеш. Биредә дә барлык хезмәткәрләрнең вакцина ясаткан, тиешле документларның булуы шарт. Шул очракта гына кунакханәләр тулы куәткә эшли ала.

➤400 кв. м мәйданнан зуррак булган җәмәгать туклануы урыннары, спорт, фитнес, сәүдә-күңел ачу үзәкләре, аквапарк, бассейн, азык-төлек белән сәүдә итмәгән кибетләрдә QR-код күрсәтеп кенә йөрү мөмкин.

➤Коронавируска каршы прививка кадатмаган һәм соңгы алты айда бу чир белән авырмаган 65 яшьтән өлкән кешеләр өчен мәҗбүри үзизоляция режимы кертелә.

kzn.ru

Алар ашыгыч медицина ярдәме кирәк булганда, вакцина ясату урынына, кибеткә, эш урынына бару, чүп түгү һәм йорт хайванын өйдән 100 метр ераклыкта булмаган арада йөртү кебек сәбәпләр белән генә өйдән чыга ала. Эш бирүчеләр исә 65 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләрен читтән торып эшләү режимына күчерергә яисә хөкүмәт карары кабул иткән чикләүләрне үтәргә тиеш булачак.

QR-код алу белән кыенлыклар килеп чыкса, 122 «кайнар элемтә» номерына шалтыратып, хәлне аңлатырга мөмкин.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Татармын! Горурмын!

Роберт МИҢНУЛЛИН, Татарстанның халык шагыйре

Мең сынаган язмыш, мең санаган
Мең алтынга торыр татарларын!
Бөек халык кына ерып бара
Гасырларның тарих кантарларын.

(«Татарларым»)

КАЙДА КҮПМЕ ТУРИСТ ЯЛ ИТКӘН?

Быел Россиянең туристик төбәкләре 58 миллионнан артык сәяхәтче кабул иткән. Бу хакта илнең туристик операторлары ассоциациясе башкарма директоры Майя Ломидзе белдерде.



Краснодар крае	14,5 млн
Мәскәү өлкәсе	10,2 млн
Кырым	8,3 млн
Санкт-Петербург	3 млн
Татарстан	2,7 млн
Екатеринбург	1 млн

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Юртаны кайчан алырга?

«Ватаным Татарстан» хәбәрчесе телефонын янына куеп йоклый. Бердән, ул будильник буларак кирәк, чөнки иртүк сәгать өчтә-дүрттә торам. Икенчедән, дөньяда вакыйгалар агышы кайвакыт шулкадәр кайнарлана: интригаларның тере шаһиты булып төнне йокламыйсың да. Шуңа күрә Техастагы берәр уку йортында атыша башлаганнар икән, янкилар атучының кем икәнен ачыклаганчыга кадәр үк, мылтык тавышы безнең өйдә дә яңгырый. Юк, алай социаль челтәрләргә бәйлелектән интекмим мин. Телефонны һәм компьютерны сүндереп куеп берничә тәүлек бернинди уңайсызлык тоймыйча да йөри алам. Ә планета сулышын тыңлап тору ул – профессиональ чирем.

Җир шарындагы хәлләр исә бер дә уңай түгел. Әле менә кичә генә Франциядә, Макронның отставкасын таләп итеп, халык Париж урамнарын тутырды. Бүген Йоханнесбургта металлурглар, хезмәт хакын күтәрүне таләп итеп, эш ташладылар. Мәйданда инә төшәрлек урын юк, каскалы кешеләр белән һәр карыш җир тулган. Чилида һәм Австралиядә, Голландия һәм Кореяда… Дөньяның бөтен почмакларында хәл киеренке. Иң начары – халыкның баш күтәрергә һәвәсләнүе түгел, начары – дефицит дигән нәрсәнең мәйданга чыгуы. Бу система да баланс югалу турында сөйли. Баланс югалдымы, система җимерелә. Бу – котылгысыз. Дефицитның хәзерге шартларда иң начары – энергетик кризис, ягулыкның сатуда бетүе. Сатуда бетү дигән сүзне ассызыклыйм, чөнки ягулыкның бар төре дә чамасыз күп хәзерге көндә.

Без, күпчелек россиялеләр, совет системасының җимерелүен күрдек бит инде. Кибетләрдә берни дә юк, ә ОРС складларында азык-төлек бозылып ята, кием-салым чери иде. Безнең өйләр дә спекулянт базасын хәтерләтә иде. Капчыгы белән сыйфатсыз чәй, центнерлы шикәр комы, оекбаш һәм эчке киемнәрнең берничә елга җитәрлек коллекциясе белән үткәрдек без социализмның җеназасын.

Хәзерге глобаль капитализмның түнтәрелеше дә шуңа охшаган. Инглизләр, машина багы тулганнан соң, канистрларга бензин тутыралар. Европадагы кибет киштәләренең бушлыгы да товар юклыктан түгел. Артык күп басылу сәбәпле, акча үз функциясен үтәүдән туктый, эш менә шунда.

Пандемия кризисы дигән сүзтезмәне мин киресенә алыштырам, кризис пандемиясе дип йөртәм. Европада ундүртенче йөздә Григорий IX указы тәэсирендә мәчеләрне үтереп бетерәләр. Моның нәтиҗәсендә чума таралып, халык кырыла башлый. Әллә кая ерак китәсе юк, үткән гасырның 60 нчы елларында коммунистик Кытайда чыпчыкларны аулап юк итеп бетерделәр һәм ачтан үлә яздылар. Исән калу өчен чыпчык импортларга туры килде. Табигый системаның бер кирпечен генә алу да зур түнтәрелешкә китерә. Хәзерге пандемия дә – менә шундый ахмак карарларның нәтиҗәсе ул. Һәм хәзер кувшиннан чыккан җенне кире куып кертү авыр инде. Вазгыятьнең куркыныч ягы шунда: кечкенә бер вакыйга да зур җимерелүгә китерергә мөмкин. Дөянең сыртын сындырган бер сабак салам дигән сүз бар бит әле. Йөкне өясең-өясең дә, авырлык күләме шул хәлгә җитә: бер сабак салам өстәүгә, хайван чыдый алмый, сырты сынып егыла. Хәзерге икътисад та шундый ноктада.

Соңгы айларда безне Америка дефолты белән куркыттылар. Конгресс хөкүмәт әҗәтләре түшәмен күтәрмәсә, Байден җитәкләгән администрация дефолт игълан итәчәк иде. Бу домино эффекты биреп дефолтлар ташкыны китереп чыгарачак һәм дөньяның финанс системасын җимерү куркынычы тудырачак иде. Ягъни Конгресс карары дөянең сыртын сындырган салам ролен үтәячәк иде. Без «Ватаным Татарстан»да алдан әйттек: бу юлы түшәмне күтәрәчәкләр, дидек. Әмма киләчәктә дефолт барыбер булачак дип тә өстәдек. Без әйткәнчә килеп чыкты: Конгресс әҗәтләр түшәмен күтәрде, әмма декабрьгә кадәр җитәрлек итеп кенә. Димәк, киеренкелек аз гына да кимемәде. Моның сәбәбе демократлар белән республикачыларның хакимлек өчен тарихта күрелмәгән тиңсез көрәш алып баруында. АКШта Байденның рейтингы шулкадәр төште: рестораннарның берсе «Байден яклылар бездә ашамасын» дигән игълан элеп куйды. Бу игълан вируслы рекламага әйләнде. Халык ул ресторанда ашау өчен ябырылып килә башлады, ашарга пешереп өлгерә алмыйлар. Лидерның абруе калмау – ил өчен катастрофа ул. Без аны Горбачев мисалында яхшы беләбез.

Минем улым – программачы. Без аның белән, өстәл янына ашарга утыргач, гел сәясәт һәм икътисад турында фикерләшәбез. Элегрәк ул минем зур катастрофаның якында гына булуы турындагы фикерләремә кискен каршы төшә иде. Соңгы айларда андый каршылык күзәтелми инде. Соңгы кичке аш вакытында ул кинәт сорап куйды: «Әти, синең, ут һәм газ бетсә, нишләргә дигән берәр планың бармы?» – диде. Бу сорау очраклы түгел, әлбәттә. Программачылар – бик кызык кешеләр алар. Бүген барысы бергә җыелып, Казандагы офиста янәшә утырып эшлиләр. Иртәгә карыйсың: берсе – Петербургта, икенчесе – Нидерландта, өченчесе Кремний үзәненә үк барып төшкән. Шуңа күрә алар кулындагы мәгълүмат – җанлы чыганаклардан. Аралашу туктамый бит. Һәм нәкъ менә алар дөньядагы эшләрнең яхшыга таба бармавын әйбәт күрәләр. Икътисадның тектоник плитәләре торган саен ныграк бәрелешә һәм безгә зур тетрәнүләр вәгъдә итә. Без бара торган юл көннән-көн сикәлтәлерәк була бара. Юк, аңа карап без әҗәл җитмичә үлмибез, әлбәттә. Сабырлыкка гына өйрәнәбез. Тормышны яхшыртуның юлларын да табабыз әле кайвакыт. Шуңа күрә паникага бирелергә кирәкми. Бернинди план да юклыгын әйткәч, «Нишләргә?» дигән каршы сорауга улым: «Юрта алып куярга була», – диде, елмаеп. «Бездә хәл аңа ук барып җитмәс дип өметләник», – дидем мин, чөнки Татарстанның потенциалы бар икәнен беләм. Әмма күңелдә барыбер шик кала. Кытайның төньягында небоскребта яшәүчеләр, электр өзелү сәбәпле, җиргә тәпиләп төшәрбез дип уйламаганнардыр беркайчан да. Ә тәпиләргә туры килде. Чит илдә бит баскычлар да күбесенчә шундый текә: кыяга менгән кебек менәсең һәм төшәсең. Өлкән яшьтәге кешенең утызынчы катка күтәрелүен күз алдына китерегез шуннан соң. Шуңа күрә юрта турындагы фикердә рациональ орлык бар.

ИГЕНЧЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

Игенчеләр бәйрәм итте. «Корстон» күңел ачу комплексына эре инвесторлар, җитәкчеләр, алдынгы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре җыелды. Аларны, елдагыча, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде.

– Мин еллык Юлламада авылны үстерүгә аерым игътибар бирдем. Биредә республика халкының дүрттән бер өлеше яши. Быел без авыр һава шартлары белән күзгә-күз очраштык. Бөтен авырлыкларга карамастан, сез чираттагы тапкыр үз һөнәрегезгә тугрылыклылык күрсәттегез. 2, 4 млн тонна ашлык җыеп алынды. Болар артында бик зур хезмәт тора. Рәхмәт сезгә! – дип мөрәҗәгать итте Рөстәм Миңнеханов.

Президент сүзләре буенча, бүген агросәнәгать комплексы тармагында халыкның 8 проценты эшли һәм тулай төбәк продуктының 6 процентын бирә.

– Республика – төп авыл хуҗалыгы продукциясе белән тулысынча тәэмин итә торган аз төбәкләрнең берсе. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы – икътисадның мөһим тармагы, – диде ул.

Президент эре инвесторлар – «Агросила», «Ак Барс», «Август – Агро», «Кызыл Шәрык – Агро», «Агроинвест», «Хузангаево», «Био – Агро», «Продпрограмма»ларның югары эш нәтиҗәләрен билгеләп узды һәм рәхмәт сүзләрен җиткерде. Матур теләкләр шулай ук терлекчеләргә дә барып иреште. Агымдагы елда республикада 1 млн 950 мең тонна сөт, 431 мең тонна ит, 1,2 млрд йомырка җитештерергә планлаштыралар. Президент алдынгылар рәтендә Кукмара (сөт җитештерү буенча лидер), Әтнә (сыерларның продуктивлыгы буенча), Балтач (мөгезле эре терлек саны буенча), Тукай (дуңгызчылык һәм кошчылык буенча), Мамадыш (мөгезле эре терлек итен җитештерү буенча иң яхшы күрсәткечләргә ирешкән) районнарын атады.

Кыр батырларын республиканың авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров та котлады.

– Рөстәм Миңнехановның Татарстан Дәүләт Советына Юлламасында агросәнәгать комплексына яңа бурычлар куелды. Терлекләрнең баш санын торгызу, агроиминиятләштерү өстенлекле бурычлар булып тора. Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча чаралар шулай ук дәвам итәчәк. Аларның барысы да тармакның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән, – диде министр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӨЙЛӘРДӘ МУЛЛЫК БУЛСЫН!

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат ҖӘББАРОВның Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көне белән КОТЛАВЫ

Хөрмәтле коллегалар, авыл хезмәтчәннәре, тармак ветераннары!

Сезне чын күңелдән Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көне белән котлыйм! Көнне-төнгә ялгап җирдә эшләүчеләр, үзләренең фидакарь хезмәтләре белән илебезнең азык-төлек иминлеген ныгытучылар, халыкны туендыручылар олы ихтирамга һәм хөрмәткә лаек.

Бу көн – авыл хуҗалыгы елына үзенчәлекле йомгак ясау. Әлбәттә, бу ел бик катлаулы булды. Елның шулай четерекле килүенә дә карамастан, кыр хезмәтчәннәре үзләренең тырышлыгы, һөнәри осталыклары нәтиҗәсендә уңышны югалтуларсыз җыеп ала алдылар.

Барлык казанышларның нигезендә хезмәт сөючәнлек, җаваплылык, сайлаган һөнәрегезгә, эшегезгә тугрылыклы булып калу, туган җиргә мәхәббәт, кыенлыкларга бирешмичә, алга куелган бурычларны үтәү һәм яңа, кыю карарлар кабул итүгә әзер булу ята. Һәм сездә бу сыйфатларның барысы да бар.

Хөрмәтле авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре! Сезгә фидакарь хезмәтегез, ирешкән уңышларыгыз өчен олы рәхмәтемне белдерәм!

Бүген агросәнәгать комплексы – республикабыз икътисадының динамикалы үсә торган секторларының берсе. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, авыл хуҗалыгы тармагының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге артканнан-арта бара. Бүген Татарстан авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитештерүгә актив рәвештә яңа технологияләр кертәләр, үз продукциясенең сыйфатын арттыралар, эш урыннары булдыралар, авыл территорияләренең инфраструктурасын үстерәләр.

Сезгә һәм якын кешеләрегезгә чын күңелдән исәнлек-саулык телим. Тормышыгызда иминлек, өйләрегездә муллык булсын, киләчәккә булган матур уй-ниятләрегез тормышка ашсын!

УРТАК ҖАВАПЛЫЛЫК

Көн кадагында

Иртәгә ни буласын фаразларга да кыен. Әйтик, әле кайчан гына коронавируслы вазгыять буенча тотрыклы төбәкләр рәтендә булсак, бүген авыручылар артуын күзәтәбез. Вазгыять киеренке. Шушы үзгәрешләр коронавируска каршы чикләү чараларының катгыйлануына китерде дә инде.

Роспотребнадзор белгечләре август башы – сентябрь азагына кадәр республикадагы санитар-эпидемиологик вазгыятьне тикшергән. Санлы мәгълүматлар мондыйрак: август аеның беренче атнасында 357 авыру очрагы теркәлсә, сентябрьнең соңгы атнасында бу сан 419га җиткән.

Аның каравы коронавируска каршы вакцина ясатучылар кимегән. Августта 200 меңнән артык кеше прививка алган, сентябрьдә андыйлар – 80 меңнән аз гына артык. Шул ук вакытта 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында прививканы узган айда 17181 кеше генә алган. Шулай итеп, сентябрь ахырына 60 яшьтән өлкәнрәк 250 меңнән артык кеше прививка ясаткан, ягъни бу планның 37 проценты. Искәртеп үтик: Татарстанда 2,4 млн кешегә прививка ясарга планлаштыралар. Бу күрсәткеч 45 процентка үтәлгән.

11 октябрьдән чикләү чаралары кертелгәч, вакцина ясатырга теләк белдерүчеләр артыр дип фаразлыйлар. Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Альмир Абашев бу җәһәттән прививка кадату өчен яңа пунктлар ачылачагын әйтте. Зур шәһәрләрдә вакцина ясату өчен кабат мобиль пунктлар эшләячәк. Мондый тәҗрибә тармак вәкилләре өчен яңалык түгел инде. Сәүдә үзәкләрендәге вакцина ясату пунктлары үз эшен дәвам итәчәк. Тик, дүшәмбе кагыйдәләре буенча, анда да QR-код белән генә кереп булачак.

– Керә торган җирдә шушы кодларны тикшереп торучылардан күп нәрсә тора инде. Сәүдә үзәкләренә керә алсагыз, керерсез дә вакцина ясатырсыз. Әгәр ишек төбендә үк борып җибәрсәләр, сырхауханә яисә башка вакцина ясату пунктында прививка кадатырга мөмкин. Җылы көннәр торганда, метро тирәләрендә мобиль пунктта прививка ясату мөмкинлеге бар, – диде Альмир Абашев.

QR-код ияләренең 11 октябрьдән соң ничек яшәячәге аңлашыла кебек. Алар иркен хәрәкәтләнә ала. Ә менә прививка ясатырга ярамаган («медотвод»ы булган) кешеләргә нишләргә?

Альмир Абашев җәмәгать урыннарына андыйларга да керү тыела дип белдерде.

– QR-код – ул вакцинацияне уңышлы узу нәтиҗәсе. Кеше авырмаса да,ниндидер зарар йоктыра, тарата ала, аның чыганагы булудан туктамый. Мондый очракта вакцинасыз кешеләр өчен куркыныч арта. Димәк, аларга җәмәгать урыннарында булу тыела. «Медотвод» бармы-юкмы – аерма юк. QR-код алу шарты бер: йә син авыру кичерәсең, йә вакцина ясатасың, – дип аңлатты министр урынбасары.

«Медотвод»сыз, кодсыз кешеләр зур сәүдә үзәге эчендә булмаган теләсә нинди азык-төлек кибетләренә, кече мәйданлы азык-төлек булмаган товарлар белән сату иткән кибетләргә, банк, даруханә, почта, мунча, җәмәгать транспорты, чәчтарашханәләргә керә ала.

Билгеле, үзең турында гына уйлый торган чордан күптән уздык инде. Белгечләр пандемия белән бәйле вазгыятьне уртак җаваплылык дип атады. Уртак эштә сынатмаска иде.

ИСТӘ ТОТ!

QR-кодны дәүләт хезмәтләре порталыннан табарга була. Иң җайлысы – телефонга «Госуслуги СТОП Коронавирус» кушымтасын урнаштыру. Шушы хезмәт аша җайлы гына итеп QR-кодны күрсәтергә мөмкин.

БЕР АВЫЛГА – БЕР СЫЕР

ЛАЕШ РАЙОНЫ ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАРЫНДА СЫЕРЛАР БЕТЕП БАРА

Борчылу

Казан читендәге авылда яшәгәч, сөт, катык, эремчек, каймак ише ризыкларга кинәнермен дигән идем. Кая ул! Ике меңнән артык шәхси хуҗалыгы булган Олы Кабан авыл җирлегендә бүген нибары 7 сыер калып бара. Аларын да кеше күзенә күрсәткәннәре юк. Элек берничә көтү чыккан авылда сыер бәйләргә җир кишәрлеге калмады, диләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күршедәге Габишево бистәсендә дә элегрәк елларда йөзләгән баш сыер асраганнар. Җирлек сәркатибе Әүзия Галимова әйтүенчә, 1500 йортлы бистәдә бүген… ике сыер исәптә. Аларына да субсидия бирә алмаганнар. Сыер асраган өчен тиешле дәүләт ярдәмен алыр өчен шәхси ярдәмче хуҗалык буларак теркәлергә кирәк, ди Әүзия Галимова.

Бер караганда, Казан янәшәсендәге Столбище, Усад, Сокуры кебек бистә һәм авылларда сыер асрау өчен мөмкинлекләр дә чамалы. Барлык чыгымнарын исәпкә алганда, сөт һәм сөт ризыкларын кибеттән сатып алуың отышлырак. Әмма, мөмкинлекләр булса, асрар идек, диючеләр дә байтак.

Элегрәк елларда үзләрен генә түгел, шәһәр халкын да авыл сөте, авыл каймагы белән сыйлап яшәгән Лаеш районы авылларында соңгы елларда сыерларның баш саны ун тапкыр кимегән! Эшләр болай барганда, районның күп авылларында мал-туар асрау тарихка гына кереп калачак.

Әле кайчан гына район авылларында 4 меңнән артык савым сыер булса, бүген барлык шәхси хуҗалыкларны кертеп саналганда 427 баш сыер калып бара.

Хикмәт Лаеш районының башкала янәшәсендә урнашкан булуында гына да түгел бугай. Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, соңгы елларда республиканың 17 районы авылларындагы шәхси хуҗалыкларда савым сыерларның баш саны кими.

Лаеш районы авыллары бу юнәлештә түбән тәгәрәүчеләр арасында иң беренчеләрдән санала. «Шәхси хуҗалыкларга дәүләт ярдәме арткан, төрле программаларда катнашып, авыл җирлегендә мини-фермалар төзү, дәүләт ярдәме белән нәселле терлек сатып алу һәм башка мөмкинлекләр булган бер вакытта, Лаеш районында узган ел дәвамында бер генә мини-ферма да төзелмәве аяныч», – ди министр.

Әтнә, Арча, Балтач районы авылларындагы һәр шәхси хуҗалыкта диярлек савым сыерлар асрауның хикмәтен дә шәһәр тирәсенә урнашу яисә көтүлек җире җитешмәүгә генә кайтарып калдыру да дөрес булмас иде. Шәхси хуҗалыкта сыер асрау – авылның киләчәген саклап калу да бит әле. Халыкны сыйфатлы сөт һәм сөт ризыклары белән тәэмин итү – элек-электән авылның ихтирамга лаек миссиясе саналган.

Изге урын буш булмый. Кибет киштәләрендә сөт тә, башка төрле сөт ризыклары да бар анысы. Үзебездә җитештерелгәннәре дә, читтән китерелгәннәре дә байтак. Атнага бер алып, суыткычта айлар буе әчеми торганнары да бар. Әмма андый сөт ризыклары кулланып, сәламәтлеккә шактый зур зыян салуыбыз да бәхәссез. Ни генә дисәк тә, шәхси хуҗалык җитештергән сөтнең файдасы күбрәк.

Чит илләрдән кертелгән пальма мае соңгы елларда 6 процентка кимесә дә, рәсми статистика күрсәтүенчә, аның әле бүген дә елына 1 миллион тоннадан артып китүе уйландыра. Белгечләр әйтүенчә, 100 мең тонна пальма мае 2 миллион тонна сөтне алыштыра. Бу кадәр пальма мае, коры сөт, үсемлек мае һәм башка катнашмалар кушып җитештерелгән сөт һәм сөт продукцияләре белән халыкның әлеге төр продукцияләргә булган ихтыяҗын тулысынча диярлек канәгатьләндереп була. Ясалма сөтнең сәламәтлеккә зыянын исәпкә алганда, авыл җирлекләрендә сыер асрауның никадәрле мөһим, файдалы һәм дәүләт югарылыгындагы иң зур бурычларның берсе булуы көн кебек ачык.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫН ЯХШЫРТУ – ТАТАРСТАН ҮСЕШЕНЕҢ СТРАТЕГИЯСЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВның ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫ

Хөрмәтле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, утырышта катнашучылар!

Кадерле татарстанлылар!

Узып баручы елда Татарстан социаль-икътисади үсешен дәвам итте. Без яңа шартларда яшәргә һәм эшләргә өйрәндек. Республика инвестицияләр җәлеп итә торган төбәк булып кала. Бездә төрле өлкәләрдә масштаблы амбициоз проектлар тормышка ашырыла, зур форумнар һәм спорт ярышлары үтә. Бүген Татарстан – яшәү һәм эшләү өчен иң яхшы төбәкләрнең берсе. Милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм гражданлык татулыгы – безнең горурлык.

Россия Федерациясенең туктаусыз үсештәге, алгарышлы төбәкләренең берсе буларак, Татарстан күпмилләтле Ватаныбызның куәтен ныгытуга зур өлеш кертә.

Без дәүләт җитәкчеләренә, илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путинга республикабызга һәрчак ярдәм итүләре һәм башлангычларыбызны хуплаулары өчен рәхмәтле.

Хөрмәтле депутатлар!

Соңгы елда Татарстанда башкарыла торган эшләребез, уңышларыбыз һәм казанышларыбыз турында сезгә алдан таратылган материалларда мәгълүмат бирелгән. Алдыбызда торган бурычларга тагын да тулырак тукталасым килә.

Халык мәнфәгатьләрен күздә тотып

Халыкның тормыш сыйфатын яхшырту, яшәү һәм эшләү өчен уңай шартлар тудыру, гражданнарның реаль керемнәрен арттыру, торак белән тәэмин итү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсе мөмкинлекләреннән һәркемнең файдалана алуы, экологиядә уңай вазгыять булдыру элеккечә үк төп максатларыбыз булып кала. Тормыш сыйфатын яхшырту – буш сүз генә түгел. Бу – Татарстан үсешенең чын стратегиясе.

Барлык эшләребез гражданнар мәнфәгатьләрен күздә тотып башкарыла. Хакимиятнең һәр баскычы һәм тармагы, бизнес һәм җәмәгатьчелек – һәммәсе әлеге төп бурычны хәл итү өчен тырышлык куярга тиеш.

Бу юнәлештә республика программалары һәм илкүләм проектлар кысаларында бик зур эш башкарыла. Быел гына да социаль әһәмияткә ия булган 1200 яңа объект төзелде һәм 3500е төзекләндерелде. Бу эшкә барлыгы 61 млрд сумнан артык акча тотылды. Саннар гына түгел, бу – тормышларында уңай үзгәрешләр булган тәгаен кешеләр, гаиләләр язмышы.

Без күпфатирлы йортлар, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, яшьләр сәясәте, юл-транспорт инфраструктурасы объектлары төзү һәм төзекләндерү кебек һәм башка шундый әһәмиятле программаларны гамәлгә ашыруны һичшиксез дәвам иттерәчәкбез.

Шәһәр мохитен үстерү өлкәсендә без зур тәҗрибә тупладык. Төзекләндерелгән, уңайлы парклар, елга ярлары һәм шәһәр бакчалары яше-карты теләп, яратып йөри торган ял урынына әверелә бара.

Җәмәгать урыннарында чисталык, тәртип саклау – муниципалитетларның турыдан-туры бурычы икәнен тагын бер кат искәртеп узам. Бу өлкәдә кайбер районнарның эшендә кимчелекләр булуы турында әйтеп киткән идек инде. Болар – Чаллы, Бөгелмә, Лаеш, Кукмара, Менделеевск һәм Балык Бистәсе районнары. Район җитәкчеләреннән, шулай ук халыкның үзеннән яңа төзелгән, уңайлы ял итү урыннарына сакчыл мөнәсәбәттә булуларын көтәбез.

Халык тарафыннан иң кирәклеләрдән дип танылган «Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыруны дәвам иттерергә ниятлибез. 2 меңнән артык ишегалдын төзекләндердек инде. Якындагы 5 ел эчендә республиканың барлык күпфатирлы йортлары ишегалларын тәртипкә китерергә тиешбез.

Сүз дә юк, хәл ителәсе бурычлар байтак әле. Торак-коммуналь хуҗалык тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе, су белән тәэмин итү, җәмәгать транспортының эше, юлларның сыйфаты, зур шәһәрләрдә юлларны, җәяүлеләр өчен сукмакларны кардан чистарту, яңгыр, кар суларын агызу җайланмаларының тиешенчә эшләве, үсештәге шәһәр һәм шәһәр яны поселокларының инфраструктура белән тәэмин ителеше, чүп чыгаруның вакытында һәм тиешенчә башкарылмавы, халыкка медицина хезмәте күрсәтү эшенә шикаятьләр һәм башка шундый мәсьәләләр халыкны аеруча борчый. Эштәге кимчелекләрне, мөмкин булган барлык чараларны күреп, тиз арада хәл итү – хакимият органнарының бурычы.

Гражданнарга үз фикерен белдерергә, киң даирәгә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашырга мөмкинлек бирә, кара-каршы элемтә механизмнарын гамәлгә ашыра торган, шул исәптән «Халык контроле», «Инцидент-менеджмент» кебек хезмәтләрне киләчәктә дә үстерү таләп ителә. Мондый платформалар дәүләт органнары эшчәнлегенең ачыклыгын арттыруда, ришвәт алу омтылышларын киметүдә нәтиҗәле чара булып тора.

Мәгариф

Яшәү урынына бәйсез рәвештә һәр балага сыйфатлы белем алу, аны каршылыксыз, сәламәт һәм социаль җаваплы шәхес итеп тәрбияләү өчен шартлар тудыру – мәгариф өлкәсендәге иң мөһим максатыбыз. Илкүләм проектларда катнашу, республика программаларын гамәлгә ашыру мәгариф инфраструктурасын шактый камилләштерергә мөмкинлек бирә. Бу эшне дәвам иттерәчәкбез.

Заманча уку-укыту контентыннан һәм технологияләреннән файдалануда мөмкинлекләрне арттыру максатында республиканың барлык мәктәпләрендә Интернет кертелде. Уку йортларын Wi-Fiга тоташтыру киләсе баскыч булачак.

Шул ук вакытта мәктәп укучыларының цифрлы нигездә эшли торган җайланмалардан файдалану күнекмәләрен үстерергә кирәк. Алар кибер-киңлекләрне үзләштерүдә хәтәр хәлләргә юлыкмаслык, алдакчы затларның «кармагы»на капмаслык, кибер-буллингка бирешмәслек, мәгълүматларның яшеренлеге ни икәнен аңларлык булсын. Бу өлкәдә шулай ук укытучыларның, ата-аналарның да белемен арттырырга, аларны балага Интернетта янаган куркынычны күреп һәм аңлап алырга, бик тиз чара күрергә өйрәтергә кирәк.

Хәзерге заман мәгариф системасының икътисадта зур тизлектә барган үзгәрешләргә һәм аның таләпләренә җайлашуы – әлеге өлкә өчен җитди сынау. Бу бурычны хәл итү максатында республикада ресурс үзәкләре челтәре булдырыла. Алар нәтиҗәле эш күрсәттеләр инде. Безнең максат – социаль-икътисади үсешнең барлык өстенлекле юнәлешләрендә ресурс үзәкләре ачу.

Татарстанның WorldSkills хәрәкәтендә катнашуы югары квалификацияле кадрлар әзерләү эшен камилләштерергә ярдәм итә. Казанда Бөтенроссия Worldskills технологияләре үзәген төзү бу юнәлештә тагын бер адым булачак. Күптән түгел һөнәри осталык буенча Австриядә уздырылган Европа чемпионатында Россиянең җыелма командасы гомумкоманда ярышларында 1 нче урын алды. Уртак җиңүгә Татарстан вәкилләре үзләреннән зур өлеш кертте. «Визуаль мерчендайзинг» һөнәре буенча җиңүче Вероника Салатова, «Медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү» юнәлешендә беренчелек яулаган Екатерина Садыйкова, «Кунакханә администраторы» һөнәре буенча җиңүче Сагдиана Рөстәмова бүген бу залда утыра. «Мобиль робототехника» компетенциясендә җиңгән Владислав Дюбанов һәм Эльдар Сейдаметов, катнашучылар арасында иң күп балл җыеп, бәйгенең иң мәртәбәле Йоса де Гой бүләгенә лаек булды.

Талантлы укучыларыбызның исемнәрен шулай ук аерып атап китәргә телим. Болар – бөтенроссия олимпиадаларында җиңгән һәм призлы урын алган Ян Бильданов, Ульяна Короткина, Артем Красков һәм хәзерге вакытта Казан федераль университеты студентлары, мәктәптә чыгарылыш имтиханнарында йөз балл җыюга ирешкән Елизавета Бельская һәм Айнур Сабитов. Егетләр-кызлар шулай ук бу залда утыра. Без сезнең белән горурланабыз һәм киләчәктә дә зур уңышларга ирешүегезне телибез! Бик зур рәхмәт сезгә!

Мәгариф системасындагы кыенлыкларның тагын берсе – кадрлар җитешмәү. Ел саен югары уку йортларын тәмамлап чыгучы 4 мең яшь белгечнең нибары өчтән бере генә балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә эшкә килә. Соңгы 3 ел эчендә генә дә, өч ел да эшләмичә, 600 яшь укытучы мәгариф системасыннан китте. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына мәктәпләрне укытучылар белән тәэмин итү һәм яшь белгечләрнең мәктәпләрдә эшкә калуы мәсьәләләрен контрольгә алуны йөклим.

2019 елдан без «Адымнар» полилингваль белем бирү комплекслары проектын тормышка ашырабыз. Ул рус, татар һәм инглиз телләрендә конкурентлыкка сәләтле белем бирүче заманча мәктәп моделе булырга тиеш. Казанда, Алабугада, Чаллыда һәм Актаныштa 4 комплекс инде эшләп килә. Тиздән ул Түбән Камада һәм Әлмәттә дә ачылачак.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына хокукый мәсьәләләрне хәл итү, туган телләр укытуда яңа дәреслекләрне куллана башлау, тәрҗемә ителгән дәреслекләрне федераль исемлеккә кертү буенча федераль үзәк белән нәтиҗәле эшчәнлекне дәвам иттерергә кирәк.

Россиядә игълан ителгән Фән һәм технологияләр елы кысаларында без производство өлкәсендә фәнни эшләнмәләрне киң файдалануга юнәлтелгән чаралар уздырабыз. Шулай да фәннең республиканың социаль-икътисади үсешенә керткән өлеше аның чын мөмкинлекләрен тулысынча ачып бетерми. Хөкүмәткә алдагы 5 елга Татарстанның фән-мәгариф комплексын үстерүгә юнәлтелгән дәүләт программасын эшләргә кирәк.

Мәгариф учреждениеләрендә куркынычсызлыкны тәэмин итү өстенлекле бурыч булып тора. Казанда һәм Пермьдә булган фаҗигале вакыйгалар һәркемнең йөрәген әрнетә. Без мәктәп биналарында физик сак хезмәтен тәэмин итү өчен өстәмә акча бүлеп бирү турында карар кабул иттек инде. Объектларны террордан саклау стандартларын кертү мәсьәләләрен профильле федераль органнар белән бергәләп эшләргә кирәк.

Моннан тыш, балалар һәм үсмерләрнең тискәре гамәлләре психологик хезмәтләргә үз эшен тагын да камилләштерү таләбен куя.

Гомумән алганда, укытучылар һәм укучыларның барлык мөрәҗәгатьләрен игътибарга алып, тиз арада чаралар күрергә, үсмерләр җинаятьчелеген булдырмау өчен актив эшләргә кирәк. Бу исә гаиләнең, уку йортларының һәм хокук саклау органнарының уртак хезмәте булырга тиеш.

Сәламәтлек

Узган елдан алып республиканың сәламәтлек саклау системасы экстремаль шартларда һәм бөтенләй башка чынбарлыкта эшли. Аз гына вакыт эчендә, медицина хезмәткәрләрен туплап, медицина ярдәме күрсәтүнең яңа системасы булдырылды.

Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе бүлекчәсе мөдире, табиб-реаниматологы Булат Фәтхуллин, Казанның 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе шәфкать туташы Алсу Цветкова, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү ярдәмче станциясе фельдшеры Радик Фәттахов бүген безнең арабызда.

Кадерле дуслар, республикабызның медицина хезмәткәрләренә үз-үзләрен аямыйча эшләгәннәре өчен сезнең аша олы рәхмәтемне җиткерәм!

Бик зур рәхмәт сезгә!

Кызганыч, пандемия дәвам итә. Бүген дә безгә вирус куркынычы яный.

Бу шартларда күмәк иммунитет булдыру гаять мөһим, ә аңа бары тик вакцинацияләү аша гына ирешеп була. Бу – пандемиягә каршы көрәшүнең бердәнбер юлы. Моны халкының күпчелеге прививка ясаткан башка илләрдәге вазгыять раслый: Германия (65%), Франция (65%), БГӘ (81%), Испания (77%), Кытай (74%), Сингапур (82%), Ка-

Яшәү урынына бәйсез рәвештә һәр балага сыйфатлы белем алу һәм шәхес итеп тәрбияләү өчен шартлар тудыру – мәгариф өлкәсендәге иң мөһим максат

Якындагы 5 ел эчендә республиканың барлык күпфатирлы йортлары ишегаллары тәртипкә китерелергә тиеш

Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ,
Республика клиник хастаханәсе баш табибы, Казан шәһәр Думасының Шәһәр халкы сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча даими комиссиясе рәисе:

– Рөстәм Миңнехановның Юлламасы Татарстан Дәүләт Советы депутатларына гына түгел, һәр кешегә юнәлтелгән. Республикада яшәгән һәрбер кеше бу Юлламада үзенә кагылган мәсьәләләрне ишетә алды. Һәркемгә карата бурыч та куелды. Президент әйткәнчә, иң мөһиме – тормыш сыйфатын арттыру һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү. Бу һәр өлкәдәге куркынычсызлыкка да карый. Без исә эпидемиологик вазгыятькә бәйле куркынычсызлык шартларын булдыру турында әйтәбез. Рөстәм Миңнеханов ассызыклап үткән тагын бер нәрсә – коллектив иммунитет булдыру. Аны булдыруда һәркем үз өлешен кертергә тиеш. Нәрсә дигән сүз бу? Һәркем коронавируска каршы вакцина ясатырга, үзендә иммунитет булдырырга тиеш. Бик авыр чорда, пандемия шартларында яшибез бит. Аны күмәк иммунитет белән генә туктатып була. Күпләр авырый, күп кешегә зыян килә. Бу мәсьәләне бергәләп җиңеп чыгарга тиеш без.

Анна МАКАРОВА,
«Волонтеры-медики» бөтенроссия хәрәкәте төбәк бүлеге координаторы:

– Пандемия чорында яшьләр, волонтерлар медицина хезмәткәрләре белән кулга-кул тотынып эшләвен һәм әлегәчә шулай дәвам итүен Президент та ассызыклады. Табибларга булган ышаныч һәм эш күләме бик зур. Хәзер вакцина ясату чоры. Һәр кешенең моңа җаваплы каравы мөһим. Волонтерлар да аңлату эшләрен күп алып бара. Рөстәм Миңнеханов та аның коронавирус белән көрәштә бердәнбер юл икәнен каткат әйтте. Сүз уңаеннан, ул «Ярдәм янәшә!» акциясендә катнашкан волонтерлар эшен дә югары бәяләде. Ышанычы һәм шундый җылы сүзләре өчен рәхмәт әйтәсе килә. Президент безгә гел теләктәшлек күрсәтә. Өметләрне аклаганбыз икән, без шат кына. Алга таба да шулай яратып эшләячәкбез.

Мария КРЮКОВА,
«Урам» экстрим-паркы җитәкчесе:

– Юлламада Президентның төзекләндерелгән ял итү урыннарын саклап тотарга кушуы күңелгә хуш килде. Бездә яңа ял урыннары төзелеп тора. Әмма аңа сакчыл караш җитми иде. Бәлки, алга таба халык ял итү урыннарына игътибарлы булыр. Нинди генә парк булмасын, республика халкы аларны яратып өлгерде. «Урам» паркын гына мисалга алыйк. Көн саен биредә йөзләгән кеше спорт белән шөгыльләнә. Экстрим паркта шөгыльләнүче яшьләр арасында яңа спорт төрләрендә (BMX, скейтбординг, баскетбол 3х3) чемпионнар да бар. Без яшь буынны паркка тартып китерүебезгә шат.
Әлеге паркның нәкъ менә Татарстанда булуы – безнең өчен зур горурлык. Экстрим-паркта төшерелгән видеолар интернетны шаулата. Күп кенә илләрдә яшәүчеләр, паркны күреп, үз фикерләрен язып калдыра. Араларында мондый урын барлыгына ышанмаучылар да бар. Безгә күпләр көнләшеп карый. Республикада яшәү өчен шартлар да, ял итү өчен мөмкинлекләр дә җитәрлек.

Асия ТИМИРЯСОВА,
Казан инновация университеты ректоры:

– Юлламада белем бирү өлкәсенә зур игътибар бирелде. Мәктәп, бакчалар төзү, яңарту, һөнәри белем бирү өчен ресурс үзәкләре булдыру, өстәмә белем бирүнең активлыгын арттыру, гаиләләргә ярдәм итү, мәктәп елларында ук һөнәр сайларга өйрәтү… Юлламада яңгыраган бу юнәлешләр барысы да киләчәккә нигез булып тора. Болар бүген эшләнә, киләчәктә дә дәвам иттереләчәк.
Президент күтәргән проблемаларны да хуплыйм. Шуларның берсе – укытучыларны мәктәпләргә беркетү чараларын көчәйтү. Бу юнәлеш буенча хәзер дә адымнар ясалды. Педагогик уку йортларына максатчан кабул итү, яшь укытучыларга ярдәм итү, торак шартларын яхшырту, өстәмә ярдәм, «Авыл укытучысы» федераль программасы… Укытучылар белем күтәргәндә үзләре теләгән программаларны сайлый ала. Хәзер менә укытучыларны мәктәпләргә беркетү җитди мәсьәлә булып тора. Әйтик, педагогик уку йортларын тәмамлаган 4 мең белгечнең нибары өчтән бере генә мәктәпкә укытырга бара. Моның буенча чаралар күрелергә тиеш булачак.
Мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсенә дә игътибар артачак. Моның өчен акча бүленгән, бу эш дәвам иттереләчәк. Мәгариф оешмаларын террористлардан саклау буенча ил күләмендә бердәм стандартлар булдырылачак. Цифрлаштыру, интернет куркынычсызлыгы темасы да читтә калмады. Бүген әти-әниләрне, балаларны мәгълүмат куркынычсызлыгына өйрәтергә кирәк булачак. Президент республикада 2022 елның Цифрлаштыру елы итеп билгеләнәчәген әйтте. Кыскасы, киләчәккә юнәлешләр билгеләнде, яңа бурычлар куелды, безгә шуларны башкару буенча эшләргә кирәк.

2020 елдан алып республиканың сәламәтлек саклау системасы экстремаль шартларда һәм бөтенләй башка чынбарлыкта яши

тар (87%), Мальта (95%). Актаныш, Яңа Чишмә һәм Ютазы районнары медицина хезмәткәрләренең һәм район җитәкчелегенең бу эшкә җаваплы каравын билгеләп китәргә телим. Монда олы яшьтәге кешеләрнең 60 проценты вакцина ясатты. Вакцинацияләү буенча иң түбән күрсәткечләр – Буа, Питрәч һәм Кукмара районнарында.

Хөкүмәткә, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, район башлыкларына, предприятиеләр җитәкчеләренә бу мәсьәләне хәл итү белән һәр көн шөгыльләнүне йөклим.

Вакцинаның 4 төре белән дә без тулысынча тәэмин ителгән. Тиешле санда вакцина ясау пунктлары ачылды. Күмәк иммунитет булдыру бары бездән тора, хөрмәтле татарстанлылар!

Шунысын да өстәп әйтим, быел илебез Хөкүмәте йогышлы куркыныч авыруларга каршы көрәшү өчен 2 млрд сум бүлеп бирде. Казан «Санитар калкан» федераль проекты гамәлгә ашырылачак 9 зур шәһәр исемлегенә кертелде: бездә ПЦР-үзәкләр ачылачак, чик аша уздыру пунктлары – «Казан» һәм «Бигеш» аэропортларында санитар күзәтчелек көчәйтеләчәк. Бик аз вакыт эчендә бар эшләрне башкарырга һәм йогышлы куркыныч чирләр һәм вирусларның таралуын туктатырга кирәк.

Катлаулы санитария-эпидемиология торышын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына диспансерлау вакытында җентекле тикшерүләр уздыру, авыруларны кисәтү һәм санаторий учреждениеләрендә тернәкләндерү программаларын киңәйтү шарт. Йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм яман шешләрне кисәтүгә аерым зур игътибар бирергә кирәк.

Сәламәтлекне ныгытуның төп нигезе – физик культураны һәм спортны үстерү. Республикада зур спорт ярышлары уздыру сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга ярдәм итә. Киләсе елда Татарстанда 50 спорт бәйгесе, шул исәптән 15 халыкара ярыш үткәреләчәк. Без аларны иң югары дәрәҗәдә оештырырга бурычлы. Шулай ук республикада зур спорт ярышларын уздыруга гаризалар бирү кампаниясен дәвам итәргә кирәк.

Токиодагы Олимпиадада югары күрсәткечләре белән сөендергән Татарстан спортчыларының исемнәрен атап китәм: фехтованиедә Марта Мартьянова – алтын, йөзүдә Александр Красных, шулай ук волейболда Максим Михайлов, Артём Вольвич һәм Валентин Голубев көмеш медаль яулады. Йөзүче-спортчыбыз Александр Красных бүген залда утыра. Александр, барлык спортчыларга тырыш хезмәтләре һәм югары казанышларга ирешүләре өчен сезнең аша рәхмәтемне җиткерәм! Уңышларыгыз яшь спортчыларны яңа җиңүләргә җилкендерә.

Татарстанда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен барлык шартлар тудырылган, 11 меңнән артык объект эшли. Кызганыч, аларның барысы да нәтиҗәле файдаланылмый. Халык спорт объектлары белән 100 процентка тәэмин ителгән кайбер районнарда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлеше республикада уртача алынган күрсәткечләрдән түбәнрәк. Болар – Югары Ослан, Ютазы, Актаныш, Яңа Чишмә, Теләче, Тәтеш, Чирмешән, Кама Тамагы һәм Баулы районнары. Мөмкин булганча күбрәк кешене, барыннан да бигрәк балаларны, спорт объектларында шөгыльләнүгә кызыксындыру – безнең бурыч.

Яшьләр

2 ел эчендә без балалар лагерьларын яңарту буенча зур эш башкардык. 23 объектны тәртипкә китердек. Быел гына да бездә 150 меңнән артык бала ял итте. Бу эшне дәвам итү мөһим.
Яшьләр белән эшләү юнәлешендәге барлык гамәлләр Татарстанда һәрбер яшь кешенең үз сәләтен, мөмкинлекләрен тулысынча ачуы һәм файдалануы максатына хезмәт итәргә тиеш. «Сәләт» хәрәкәте, «Созвездие-Йолдызлык», «Наше время – Безнең заман», Студентлар лигасы яшьләр проектлары уңай нәтиҗәләр бирде. Җәмәгать берләшмәләренә һәм аларның башлангычларына ярдәм итүне туктатмаячакбыз.

Шулай ук инфраструктураны камилләштерү эшен дәвам иттерәчәкбез. Республика районнарында шартлар тудыру белән бергә, киләсе елда «Сәләт»нең Кырымда мәйданчыгын ачабыз, яшүсмерләр клубларын, яшьләр үзәкләрен, шулай ук креатив мәйданчыкларны үзгәреп кору эшен дәвам итәчәкбез.

Бу эшнең күркәм үрнәге буларак «Урам» экстрим-паркын – урам культурасы үзәген төзүне күрсәтергә мөмкин. Мәйданчыкларының сайланышы һәм инфраструктурасының сыйфаты ягыннан, дөньякүләм дәрәҗәдә алганда, ул тиңдәшсез комплекс булып тора.

Яшь буынны мәдәни мирас белән таныштыруда илебез Президенты Владимир Владимирович Путин башлангычы белән гамәлгә куелган «Пушкин картасы» зур мөмкинлекләр ача. Татарстанда «Пушкин картасы»н 300 меңнән артык кеше алачак, һәр катнашучыга, үзе сайлап, республиканың 80нән артык мәдәният учреждениесендә булу мөмкинлеге бирелә.

Мәдәният тармагы инфраструктурасын киләчәктә дә камилләштерү өлкәсендә, хәзерге бинасын яшьләргә тапшырып, заманча яңа татар театрын төзү һәм шулай ук киләчәктә, уйлавымча, популяр җәмәгать мәйданчыгына әйләнәчәк тиңдәшсез архитектура истәлеге – Ушкова йортын реставрацияләү һәм кайбер башка күренекле объектларны төзекләндерү бурычы тора.

Тулаем алганда, мәдәният учреждениеләре эшчәнлегендә иҗат берлекләренең мөмкинлекләрен киңрәк файдаланырга кирәк.

Гаилә

Гаиләләргә, беренче нәүбәттә балалы, яшь, күпбалалы һәм тәрбиягә бала алган гаиләләргә ярдәм күрсәтү – безнең эшебездә һичшиксез өстенлекле юнәлеш. Илебез Президенты Владимир Владимирович Путинның өстәмә түләүләр турындагы карарлары халыкта уңай бәяләнә. Президентыбызга бик зур рәхмәт! Нык гаилә – көчле дәүләт һәм күпмилләтле халкыбыз бердәмлеге нигезе – ул милли-мәдәни традицияләрне һәм туган телне саклаучы булды һәм шулай булып кала да. Кыйммәтле рухи хәзинәләр һәм традицияләр, тәҗрибә һәм гыйлем нәкъ менә гаиләдә кадерләп саклана һәм буыннан-буынга тапшырыла килә.

Хезмәт династияләре вәкилләре корган гаиләләр буыннар арасындагы ныклы бәйләнешнең күркәм үрнәге булып тора. Мисалга Зеленодольскида яшәүче, нәселләре белән укытучы һөнәренә тугры булган күпбалалы Поповлар гаиләсен, берничә буыны республиканың зур сәнәгать предприятиеләрендә хезмәт куйган Хаҗиморатовлар һәм Шишковлар гаиләләрен китерергә була.

Татарстанда бөтен Россия күләмендә танылган, зур хөрмәткә лаек булган гаиләләр бар. Алар арасында – Балтачта яшәп, 15 бала тәрбияләүче, «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән Мөхәрләмовлар гаиләсе.

Бүген бу парлар залда утыра.

Күптән түгел илебез Президенты Владимир Владимирович Путин Указы нигезендә Әтиләр көне гамәлгә куелды һәм халык тарафыннан гаять уңай кабул ителде. Шуңа өстәмә буларак, гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен күтәрү максатында Татарстанда яңа дәүләт бүләге – «Родительская доблесть – Ата-ана фидакарьлеге» медален гамәлгә кую турында карар кабул ителде.

Экология

Уңайлы яшәү тирәлеге булдыру – яхшы тормыш өчен иң мөһим шартларның берсе. Республикада «Экология» илкүләм проекты һәм республика программалары кысаларында зур эшләр башкарыла. Бүгенге көндә без «Иделне чистарту» федераль проекты кысаларында чистарту корылмаларын төзүне дәвам иттерергә, шулай ук ләм кырларын бетерү юнәлешендә эшләргә тиеш.

Соңгы вакытларда гражданнардан һаваның сыйфатына карата, аерым алганда, Казан шәһәренең Көнчыгыш чүп полигоны янында, шулай ук Питрәч һәм Лаеш районнарында кошчылык фабрикаларының үз эшчәнлек калдыкларын табигатькә ташлавы белән бәйле рәвештә шикаятьләр килә.

Мондый хәлгә түзеп торырга ярамый, әлбәттә. Самосырово поселогы янындагы чүплекне бетерү эшенә тотындык инде.

Барлык предприятиеләр җитәкчеләренә һавага һәм сулыкларга зыян китерүне булдырмау өчен калдыкларны эшкәртүнең алдынгы технологияләрен файдалануга кертү кирәклеген искәртәм.

Хокук саклау һәм күзәтчелек органнарының бу мәсьәләне игътибар үзәгенә алуларын сорыйм.

Балтачта яшәп, 15 бала тәрбияләүче Мөхәрләмовлар гаиләсе бөтен Россия күләмендә танылды

Республикада экология мәсьәләләренә битараф булмаган кешеләр күп. Аларны, хаклы рәвештә, әйләнә-тирә мохитне саклау эшенең каһарманнары дип атарга була. Азнакай районында яшәүче Рафиковлар гаиләсе, әйтик, 2009 елдан үзләренең Иркле авылы тирәсендә 200 гектардан артык җирдә агач утырткан. Әлмәт районында яшәүче Пётр Игнатьев туган авылында үз көче белән ял паркы ясый, агачлар, үсемлекләр утырта, елга ярын ныгыта һәм инештә балык үрчетә. Экологиягә кагылышлы белемнәрне арттыруга «Чиста булачак» иҗтимагый хәрәкәтендә катнашучы балалар да зур өлеш кертә.

Мондый кешеләрдән үрнәк алырга кирәк. Бүген алар залда утыралар.

Экология дигәндә, хәзерге заманда чиста сулы елгалар, чиста һава һәм урманнар гына күздә тотылмый. Бу – икътисадка куелган заман таләбе. Товарларның һәм оешмаларның экологик яктан чисталыгы – аларның конкурентлыкка сәләтле булуы күрсәткечләренең берсе, кулланучылар ихтыяҗы.

Безнең алда, 2026 елда углеродка халыкара салым кертү планлаштырылу белән бәйле рәвештә, углерод калдыклары йогынтысын киметү чаралары комплексын эшләү, шулай ук ресурсларны кабаттан эшкәртүне арттыру күздә тотылган циркуляр икътисадны үстерү бурычы тора. Хөкүмәткә югары уку йортлары, Фәннәр академиясе һәм предприятиеләр белән бергәләп программа төзер өчен тәкъдимнәр әзерләүне йөклим.

Сәнәгать

Халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм яшәү дәрәҗәсен күтәрүнең нигезен нәтиҗәле икътисад тәшкил итә. Тотрыклы икътисади үсешне тәэмин итү – хәзерге чорда безнең төп бурыч. Республика өчен әһәмиятле берничә инвестиция проекты нефть, газ һәм химия комплексында гамәлгә ашырыла.
Быел водород, майлау материаллары производстволарын, каталитик крекинг җайланмаларын эшләтеп җибәргән, ел азагына кадәр 53 млрд сумлык тагын 4 җайланманы файдалануга кертәчәк «Татнефть» компаниясенә рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез.

ТАНЕКО комплексына ел ахырына компания керткән инвестицияләрнең гомуми күләме 470 млрд сум тәшкил итәчәк. «ТАНЕКО» һәм «ТАИФ-НК» акционер җәмгыятьләрендә проектларны гамәлгә ашыру республикада ел саен 23 млн тоннадан артык нефть эшкәртергә мөмкинлек бирәчәк.

«Түбән Кама нефтехим» һәм «Казан органик синтез» компанияләре алдында үз энергия җитештерү җайланмаларын эшләтеп җибәрү, производстволарны үстерү, ЭП-600 олефин комплексын төзү бурычы тора.

Әлеге һәм башка әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруны киләчәктә дә тәэмин итү республика Хөкүмәте һәм «СИБУР Холдинг» компаниясе арасында төзелгән килешүдә карала.

Полимерларны эре тоннажлы җитештерү белән генә чикләнмичә, яңа эшкәртү производстволары да булдырырга кирәк. Быел «ТатхимПласт» полимер компаундлары производствосының 2 нче чираты эшли башлады. Октябрьдә «Алабуга-Җепсел» ПАН-прекурсор производствосын ачу планлаштырыла. Киләсе елда «Данафлекс-Алабуга»да кабаттан эшкәртү өчен яраклы пленка һәм йомшак төрү материаллары җитештерү проектын үтәүне дәвам иттерәчәкбез.

Республиканың машина төзү комплексы тотрыклы үсештә.

КАМАЗ – илебезнең автомобиль төзү тармагында беренчеләр сафында.

Завод җитәкчелегенә дөньяның алдынгы машина төзүчеләре белән беррәттән туктаусыз алгарышка омтылуы һәм яңалыкларны кулланышка кертүе өчен рәхмәт сүзләремне җиткерәм. К-5 буыны автомобильләренең, Мәскәү халкына хезмәт күрсәтә торган электробусларның сатып алучыларда кызыксыну тудыруын тармакның уңышы буларак мисалга китерергә мөмкин. Компания гибридлы көчәнеш җайланмалы К-6 йөк машиналарының перспектив буынын һәм яңа төр карьер үзбушаткычлары чыгарырга ниятли.

Казанның С.П.Горбунов исемендәге авиация заводына яңарту эшләрен тулысынча тәмамларга һәм дәүләтнең оборона заказын үтәүне тәэмин итәргә кирәк.

Казан вертолет заводының бурычы – предприятиене тулы көченә эшләтүне тәэмин итү, Ансат һәм Ми-38 вертолетларын серияле җитештерүгә күчү.

Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводына, хәрби техника җитештерү белән беррәттән, гражданнар өчен чыгарыла торган продукцияне – яңа «Метеор-2020» проектының су асты канатлары булган һәм ял оештыру судноларын эшләүне арттырырга кирәк.

«Форд Соллерс» компаниясендә соңгы 2 ел эчендә җитештерүнең күләме 1,5 тапкырга артты, бик аз вакыт эчендә серияле төстә люкс – AURUS класслы беренче Россия автомобиле җитештерелә башлады.

Нефть-газ тармагындагы һәр унынчы компрессор җайланмасы «Казан компрессор машиналары төзү заводы»нда чыгарыла. Шулай итеп, быел бирედә «Себер көче - 2» проекты өчен газ кудыру агрегатлары эшләнә башлады.

90 еллык тарихы булган Казан медицина инструментлары заводы бүгенге вазгыятькә, заман таләпләренә бик тиз яраклашты. Россиядә полимераз чылбырлы реакция (ПЦР) тестлары алу өчен кулланыла торган һәр өченче зонд безнең заводта эшләнә.

«Вакууммаш» – илебездә вакуум җиһазлары җитештерүдә әйдәп бара торган компания. Гомумән алганда, «Көнчыгыш» космодромы өчен барлык вакуум җиһазлары бирედә эшләп чыгарыла.

«Алнас» компаниясе – Америкада нефть чыгару җайланмалары сату базарын үзләштерелә.

Чит ил партнерлары арасыннан республикада инде дүртенче заводын төзи башлаган «Хайер» компаниясен һәм шулай ук экспорт юнәлешендә уңышлы эшли торган «Кастамону» компаниясен билгеләп үтәсем килә. Бүгенге көндә компаниянең Алабуга заводы продукциясе дөньяның 35 иленә сатуга чыгарылды, экспорт өлеше 2025 елга 30 проценттан артып китте.

Илебез Президенты тарафыннан оборона-сәнәгать комплексын диверсификацияләүне 30 процентка җиткерү бурычы куелды. Республиканың 27 предприятиесеннән бары тик 5есендә генә әлеге дәрәҗәгә ирешелде. Дәүләт оборона заказы күләме кимү шартларында безгә җитештерүдәге мөмкинлекләребезне һәм кадрлар потенциалын саклап калу һәм аны гражданнар продукциясе җитештерүдә нәтиҗәле файдалану зарур. Әлеге юнәлештә «ПОЗиС» заводы яхшы үрнәк булып тора.

Татарстан тарихында беренче тапкыр буларак энергетика комплексында 2 ГВт көчәнешкә исәпләнгән электр станцияләрен бер үк вакытта төзү һәм яңартып кору буенча проектлар тормышка ашырыла. Зәй дәүләт район электр станциясенең өлеше – иң зурысы.

Тулаем алганда, безнең сәнәгать комплексы алдында җитди бурычлар тора.

Беренчесе – нәтиҗәлелекне арттыру. Бу – шул исәптән хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, инновацияләр кертү, җитештерүне цифрлаштыру. Әлеге мәсьәләләр күптән түгел булып узган Kazan Digital Week форумында бик җентекләп каралды. Тикшерену йомгаклары буенча түбәндәге нәтиҗәләр ясалды: безнең предприятиеләрнең цифрлы нигездә эшләүгә күчү индексы биш баллы шкалада 2,7 баллны тәшкил итә, һәр дүртенче предприятиедә генә технологик инновацияләр кулланышка кертелә. Күпчелек компанияләр бу мәсьәлә белән өлешчә генә шөгыльләнә яисә бөтенләй шөгыльләнми. Бу – безнең барыбызга да киләчәктә әлеге юнәлештә эшне тизләтергә дигән кисәтү.

Икенчесе – экспортны арттыру. Республика экспорты структурасының 70 процентын диярлек нефть, нефть продуктлары һәм нефть химиясе продукциясе алып тора. Моннан тыш, бездә кереме 1 млрд сумнан артык булган һәм өстәмә бәягә салым түләүдән азат ителгән предприятиеләр бар. Беренче чиратта, химия, машина төзү тармакларының югары сыйфатлы эшкәртү сәнәгате продукциясен сатуны арттырырга кирәк. Хәләл-индустрия шулай ук зур мөмкинлекләргә ия.

Өченчесе – импортны алмаштыру. Бүгенге көндә импортның өчтән бер өлешен машина төзү тармагы продукциясе тәшкил итә. Бу өлкәгә нәкъ менә безнең машина төзү предприятиеләр күпләп инвестицияләр кертергә тиеш.

Дүртенчесе – сәнәгать куркынычсызлыгы. Соңгы елларда Татарстанның сәнәгать объектларында җәмәгатьчелектә көчле яңгыраш алган берничә вакыйга булды. Алар өчен оешма җитәкчеләре шәхсән җаваплы.

Бишенчесе – кадрлар белән тәэмин ителү. Әлеге мәсьәлә бүгенге көндә республиканың бик күп компанияләрендә җитди борчылу тудыра. Бу темага багышлап без якын арада Куркынычсызлык советы утырышы уздырачакбыз.

Хөкүмәткә предприятиеләр белән берлектә алда әйтеп кителгән мәсьәләләрне хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләүне йөклим. Болар барысы да безнең икътисадыбызның конкурентлыкка сәләтен тәшкил итүче мөһим өлкәләр.

Эшмәкәрлек

Бүгенге көндә бизнеска булышлык күрсәтүнең Татарстанда төзелгән инфраструктурасы резидентлары республикадагы сәнәгать җитештерүенең 10 проценттан артыгын тәшкил итә. «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисади зоналарының, «Мастер» Кама индустриаль паркының, «Химград» технополисының эш нәтиҗәләре югары.
Муниципаль сәнәгать мәйданчыкларыннан да без тиешле дәрәҗәдә нәтиҗәле эш көтәбез. Дәүләт тарафыннан акча бүлеп бирелүгә дә карамастан, кайбер районнардагы эш һич канәгатьләнерлек түгел. Бу – Яңа Чишмә, Буа, Актаныш, Мамадыш районнары.

Шул ук вакытта «Зеленодольск» (900 эш урыны) һәм «Кама Аланы» (800 эш урыны) сәнәгать парклары яхшы күрсәткечләргә иреште.

Быел сәнәгать мәйданчыкларына дәүләт ярдәме күрсәтүдә яңа чаралар кулланыла башлады. Безнең бурыч – резидентлар санын һәм эшнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм, иң мөһиме, бу мәйданчыкларда яңа эш урыннары булдыру максатында алардан актив файдалану.

Республиканың алгарышлы биш социаль-икътисади үсеш территориясе буенча да яңа резидентлар җәлеп итүгә кагылышлы шундый ук бурыч тора.

Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгының, социаль-икътисади үсеш территорияләре урнашкан муниципаль берәмлекләр башлыкларының нәкъ менә шуңа тиешле игътибар бирүен сорар идем. Һәрбер инвестиция проекты үтәлешен аерым контрольгә алырга кирәк.

Барлык хакимият органнары өчен уңайлы инвестиция климаты булдыру, бизнеска административ йогынтыны киметү шулай ук өстенлекле мәсьәләләр булып кала. Бизнеска кагылышлы билгеле бер хосусый мәсьәләләр белән шөгыльләнү аша без тулаем эшлекле даирәнең һәм икътисадның системалы проблемаларын хәл итәбез. Әлеге максатларда республиканың хакимият органнарында, гражданнарны кабул итү көне мисалында, эшкуарларны кабул итү өчен бердәм көн билгеләргә һәм уздырырга кирәк.

Без эшкуарлык рухын үстерүгә сабый чактан ук зур игътибар бирергә тиеш. Мәктәпләрдә спорт секцияләре, музыка сыйныфлары белән беррәттән, бизнес күнекмәләре бирү түгәрәкләрен дә оештырырга кирәк. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә шәһәрләр өчен генә түгел, ә авыллар өчен дә тиешле мәгариф программасын эшләүне йөклим.

Үзмәшгульләр институты үзенең нәтиҗәле булуын исбатлады. Аларга ярдәм күрсәтү эшен дәвам иттерергә кирәк. Безнең бурыч – үзмәшгульләр үз бизнесын үстерә, ә киләчәктә эшкуарлар булып китеп, яңа эш урыннары булдыра алсын өчен барлык шартларны тудыру.

Бу елны бик күп гражданнарыбыз финанс пирамидаларында үзләренең акчаларын югалтты. Моның төп сәбәбе республика халкының финанслар өлкәсендә белеме аз булуга кайтып кала. Хөкүмәткә тиешле федераль структуралар һәм «Татмедиа» агентлыгы белән берлектә гражданнарның белем дәрәҗәсен һәм аларның алдакчылардан саклану ысуллары һәм алымнары турында хәбәрдарлыгын арттыру буенча комплекслы чаралар эшләүне йөклим. Безнең хокук саклау органнарына алдан күреп эш итәргә, финанс пирамидаларын булдырмау яисә аларның эшчәнлеген башлангыч этапта ук туктату мәсьәләләрендә катгый позициядә булырга кирәк.

Электрон сәүдәне үстерү өлкәсендә соңгы ике ел гаять алгарышлы булды. Татарстан сатучыларының «Вайлдберриз», «Озон» һәм «Казан-экспресс» мәйданчыкларында товар әйләнеше 19 млрд сумнан артып китте. Узган ел 3,5 млрд иде. Татарстан сатучыларының саны быел 9500дән артып китте. Узган елда 3500 иде. Әлеге этапта интернет-сәүдә белән шөгыльләнүче халыкара һәм федераль компанияләр һәм транспорт-логистика провайдерлары белән хезмәттәшлек оештырырга, шулай ук бизнесны электрон мәйданчыкларда эшләргә өйрәтүне дәвам иттерергә кирәк. Мондый эш алып барыла инде. Бу – кирәкле һәм әһәмиятле юнәлеш.

Авыл хуҗалыгы

Корылык сәбәпле быел республикада Гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Һава температурасы һәм явым-төшемнәр күләме ягыннан хәл 2010 елга охшаш булды. Шушы вакыт эчендә дым җыю, дым саклау һәм алдынгы технологияләрне кулланышка кертү буенча зур эш башкарылды. Һәм ул яхшы нәтиҗәләр бирде. Моны без Минзәлә районыннан «Дәүләтов», Арчадан «Казансу», Буадан «Авангард», Балтач районыннан «Дуслык» хуҗалыклары, шулай ук «Агрокөч», «Чистай» һәм «Агроинвест холдинг» компанияләре мисалында ачык күрәбез.
Тулаем алганда, безнең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре тарафыннан 2,4 млн тонна ашлык җыеп алынды. Бу исә, 2010 ел белән чагыштырганда, 3,5 тапкырга диярлек күбрәк. Авыл хезмәтчәннәренә игелекле, әмма катлаулы хезмәтләре өчен олы рәхмәтемне җиткерәм!

Җирне ашлау – гектарына кимендә 70 кг ашлама кертү, шулай ук дым саклау эшен дәвам иттерү гаять мөһим.

Һичшиксез, әлеге мәсьәләне бары тик мелиорация чаралары белән генә хәл итеп бул-

Коры, катлаулы ел булуга карамастан, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре 2,4 млн тонна ашлык җыеп алды

Айрат ГЫЙМАДЕТДИНОВ,
Татарстан Иҗтимагый палатасының икътисад һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеге өчен инфраструктура комиссиясе рәисе,
«АКФ «Аудэкс» җәмгыяте генераль директоры:
– Юлламада гомуми сүзләр генә сөйләнмәде, ә эшнең нәтиҗәсен күрсәтә торган төгәл саннар китерелде. Мәсәлән, республикадагы маркет-плейсларның гомуми товар әйләнеше берничә тапкыр үскән: 3,5 млрд сумнан 19 млрд сумга кадәр. Һәм әлеге маркет-плейслар аша үз товарларын сатучы Татарстандагы эшмәкәрләр саны да бермә-бер арткан. Бу, әлбәттә, бик мөһим һәм зур күрсәткеч, чөнки елдан-ел онлайн сату объектлары саны, маркет-плейсларның роле артачак кына. Ә ваклап сату кимер дип уйлыйм. Татарстанның әлеге тармакта мондый үсеш күрсәтүе – бик яхшы күрсәткеч. Моңа кадәр кабул ителә торган үсешкә ярдәм итү чаралары, эшмәкәрләрне укыту – бездә барысы да бушлай оештырыла. Аларда эшмәкәрне көтәләр, эшләр өчен барлык шартлар тудыралар. Ә маркет-плейс ул – үз продукцияң белән бөтен илгә чыгу юлы.
Шулай ук Юлламада сәнәгать мәйданнарында эш урыннары арту буенча китерелгән саннар да күңелгә хуш килде. Районнарда кайдадыр уңышлар бик яхшы, кайдадыр арттарак калалар әле. Ләкин уңышлы сәнәгать парклары булу моның өстенлекле юнәлеш булуы турында сөйли. Һәм бик үсеш алмаганнарга алардан үрнәк алу мөмкинлеге бар. Үрнәк мисаллар – башка районнарга маяк.

Данис ШАКИРОВ,
Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе:
– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Татарстан Дәүләт Советына Юлламасын тәмамлаганда әйткән сүзләрен җанисәп кампаниясенең шигаре итәрлек. Ул: «Без бергә, безнең көч – бердәмлектә», – диде. Бу сүзләр татарларга бик туры килә. Җанисәп – безнең милләтебез өчен мөһим вакыйга. Быел халык санын алганда электрон рәвештә дә үзең хакында мәгълүмат калдырып була. Җанисәпне кеше санын алу дип кенә кабул итмәскә кирәк. Бу чорда үзебезнең бердәмлекне күрсәтәчәкбез. Әлеге җаваплы чорда һәр татарның актив булуын сорыйбыз. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә аңлату эшләре алып барыла. Аларның да бит, кайда яшәсәләр дә, күзләре Татарстанга, Казанга төбәлгән. Алар безгә, без аларга тартылабыз. Сентябрь аенда узган «Милләт җыены» безнең бердәмлекне, татулыкны дәлилләде. Җанисәп вакытында да бердәмлегебезне күрсәтсәк иде.

Мөнир ГАФИЯТУЛЛИН,
Россия Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары:
– Рөстәм Миңнеханов бу юлы да вазгыятькә тирән анализ ясады. Безнең алга бик күп бурычлар куйды. Аларга зур игътибар бирергә кирәк булачак. Иҗтимагый палата эшчәнлегенә аерым тукталып, уңышларыбызны, бурычларыбызны әйтте. Мин моның белән аеруча горурландым.
Төзелеш тармагына килгәндә, ул 31 млн кв. метр торак төзү бурычын әйтте. Шуңа күрә төзүчеләр алдында бик зур бурыч тора. Балалар бакчасы, мәктәпләр төзергә кирәк. Президент илкүләм проектларга да зур игътибар бирде. Алга таба Иҗтимагый палата шушыларның барысын да искә алып эшләргә тиеш була. Безнең төп бурыч – тәкъдимнәр әйтү. Шуңа күрә безгә, җыелышып, төзүчеләргә нинди ярдәм күрсәтә алуыбыз турында уйларга кирәк булачак. Иң элек илкүләм проектларның үтәлешен карап, барлап чыгарга тиеш булабыз. Кайдадыр ниндидер тоткарлыклар булса, төп игътибарны шул тарафка юнәлтү сорала. Өстенлекне нәрсәгә бирергә тиеш булуыбызны белергә кирәк. Һәр проектка тирән анализ һәм алга таба эш тәртибен төзү – безнең беренчел бурычыбыз.

Эмиль ГОБӘЙДУЛЛИН,
Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәгенең генераль директоры:
– Президентның Юлламасы барлык өлкәләргә дә яңа юл күрсәтә. Юлламада гаилә тотрыклыгы, сәламәтлек, мәдәният, спорт темалары буенча да әйтелде. Чарага һөнәри осталык буенча Европа чемпионнарын чакыруны да хуплыйм. Сүз сентябрь ахырында Австриядә узган Европа чемпионатында җиңү яулаган яшьләр турында бара. Татарстаннан 17 кеше 16 медаль яулады. Башка яшьләргә дә үрнәк бу. Уку йортлары, без дөрес юлдан барабыз дип уйлыйм. Безнекеләр бөтен дөньяда үзләрен иң яхшы белгечләр итеп күрсәтә. Киләчәктә икътисад өлкәсендә яхшы белгечләр тагын да күбрәк булырга тиеш һәм шуның буенча эшлибез.
Хәзерге вакытта һөнәри уку йортларына укырга керү системасы үзгәрде.
9 нчы сыйныфны тәмамлаган укучыларның 60 проценты техникумнарга укырга керә. Монда «Ворлдскиллс» чемпионатында җиңүчеләргә охшарга тырышуның да өлеше бар. Элек, техникумнарга «икеле» һәм «өчле»гә укыганнар бара, дип әйтсәләр, хәзер алай түгел. Күбесе – «дүртле» һәм «бишле»гә укучылар. Конкурслар зур. Бер урынга 6–8 кеше дәгъва кыла.

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында республикада яшәүче барлык халык вәкилләренә төрле яклап ярдәм күрсәтүгә зур игътибар бирелә

маячак. Төп игътибарны авыл хуҗалыгы фәненә бирергә кирәк. Без ашлыкның корылыкка бирешми торган сортларын һәм инновацияле агротехник чаралар тәкъдим итүне көтеп калабыз.

Моннан тыш, авыл хуҗалыгында хәвефләрдән саклану алымнарын тагын да активрак кулланышка кертү таләп ителә. Быел нибары 10 процент чәчүлек иминиятләштерелгән. Авыл хуҗалыгы министрлыгына бу мәсьәләне аерым контрольгә алырга кирәк.

Татарстан – сөт җитештерүдә Россия Федерациясендә алдынгыларның берсе. Мамадыш, Әтнә, Саба һәм Кукмара районнарында савым сыерларының баш саны ишәя бара.

Шул ук вакытта кайбер муниципалитетларда тискәре тенденция күзәтелә. Кама Тамагы, Зәй, Аксубай, Теләче, Спас районнарында савым сыерларының баш саны бик күпкә кимегән. Кайбер районнарда, мәсәлән, Чүпрәле, Югары Ослан, Баулы, Спас районнарында фермалар төзү буенча бер генә инвестиция проекты да һәм, билгеле инде, алга таба терлекчелекне үстерү перспективалары да юк. Азнакай, Алексеевск, Баулы һәм Зәй районнарында яхшы үрнәкләр бар. Баш санын киметүгә юл куйган районнарга Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә аны торгызуның юл картасын әзерләргә кирәк булачак.

Хәзерге вакытта Татарстанда «хәләл» продукция җитештерүче 100дән артык компания бар. Шуның 20се – экспортка эшли. Хәләл индустрияне үстерү, хәләл продукция экспортын киңәйтү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Дәүләт ярдәме күрсәтелү нәтиҗәсендә соңгы елларда кече хуҗалык формаларының дәрәҗәсе бик нык үсте. Без, һичшиксез, әлеге эшне дәвам иттерәчәкбез. Бүген без залга республиканың авыл хуҗалыгын үстерүгә мөһим өлеш керткән фермерларыбызны чакырдык. Алар – Азнакайдан Айрат Габдрахманов, Чүпрәле районыннан Равил Бикчуров, Буадан Петр Лапшин, Кукмарадан Таһир Бариев һәм шулай ук Аксубайдан Әлфирә Шакирова.

Авыл хуҗалыгында куллану кооперативларын үстерү шулай ук актуаль бурычларның берсе булып кала. Бүгенге көндә кулланучылар җәмгыятьләре барлык районнарда да оештырылды. Ләкин Кама Тамагы, Лаеш һәм Алабуга районнарында авыл хуҗалыгы продуктларын әзерләүне оештыруда җитешсезлекләр бар. Чимал эшкәртү, продуктларны җитештерүчедән кулланучыга җиткерү өчен районнар арасында кооперацияне җайга салу эшен дәвам итәргә кирәк.

Яз көне сезонлы яшелчәләргә кискен рәвештә бәяләр үсте. Киләчәктә мондый хәл кабатланмасын өчен безгә яшелчә утыртуны арттыру белән генә чикләнмичә, продуктларны эшкәртү һәм саклау өчен тиешле инфраструктура формалаштыру, шулай ук үзләреннән артып калган авыл хуҗалыгы продуктларын халыктан сатып алу буенча хезмәттәшлекне активлаштыру таләп ителә. Әлеге эшне көз көне, уңыш җыяр алдыннан гына түгел, ә ел дәвамында алып барырга кирәк. Татарстанның кулланучылар җәмгыятьләре берлегенә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, район башлыклары белән бергәләп бу эшне оештыруны йөклим.

Төзелеш

Киләсе 10 елга безнең алда 31 млн кв. метр торак төзү буенча җитди бурыч тора. Һичшиксез, моңа бик күп акча кирәк булачак. Илкүләм проектлар һәм адреслы федераль программалар белән берлектә илебез Хөкүмәте тарафыннан «инфраструктур меню» дип аталган өстәмә чаралар кабул ителде. Безнең бурыч – әлеге яңа чаралардан мөмкин булганча тулы файдалану.
Шул ук вакытта еш кына йорт төзүчеләрнең мәнфәгатьләре территорияне үстерүнең стратегик планнары белән тәңгәл килми. Нәтиҗәдә, агломерация эчендә транспорт челтәренә чамадан тыш йөкләнеш, инженерлык һәм социаль инфраструктураның җитәрлек булмавы, хезмәт базарында тигезлек сакланмау күзәтелә.

Торак төзелеше мәсьәләләре һәм территорияне үстерү программаларының бер-берсе белән килештерелгән булуы шарт. Республикада нәкъ менә әлеге юнәлештә Казан шәһәреннән чыгу магистральләрен төзү, Зур Казан боҗрасы, «Зур Зеленодольск» проекты һәм Лаеш узелын үстерү буенча федераль үзәк белән эшләүне дәвам итәргә кирәк.

Тулаем алганда, Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте ярдәме белән республика илебезнең транспорт каркасын формалаштыруда катнаша. Бу – Идел елгасы аша күпер салып, М-12 Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Екатеринбург, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узучы М-7 автомобиль юлларын һәм Шәле – Баулы автомобиль магистрален төзү.

Быел Татарстанның Әтнә, Зеленодольск һәм Питрәч районнары Җир һәм күчемсез милек турында бердәм мәгълүмат ресурсы төзү буенча сынау проектына кертелде. Бу сервис федераль һәм төбәк мәгълүмат системаларыннан территория турында иң төгәл белешмәләр алырга мөмкинлек бирәчәк. Киләсе елга бурыч – сервиска республиканың барлык районнары турында белешмәләрне кертү.

Милләтара һәм динара дуслык

Милләтара һәм динара тынычлык һәм гражданнар арасындагы татулык – республиканың барлык казанышлары нигезе, шулай ук киләчәк уңышларыбызның аерылгысыз өлеше булып тора.

Яшәү һәм эшләү өчен уңайлы шартлар булдыруга юнәлтелгән уртак хезмәтебез, төптән уйланылган этноконфессиональ сәясәт – болар барысы да дуслык һәм үзара аңлашып яшәү мохите булдыруга ярдәм итә.

Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында без республикада яшәүче барлык халык вәкилләренең туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүгә, күпмилләтле халкыбызның бердәмлеген ныгытуга, шулай ук татар милләтен берләштерүгә, ватандашларыбызга һәрьяклап ярдәм күрсәтүгә аеруча зур игътибар бирәбез. Һәр милләткә үзенчәлеген саклау, мәдәниятен үстерү һәм башка халыкларның мәдәнияте белән танышу мөмкинлеге бирү гаять мөһим. Һәркемнең кабатланмас шәхес булуын тану һәм үзара хөрмәт – гражданнар арасындагы бердәмлекнең нигезе.

Илебез халкы традицияләренең асылын кешелеккә хас төп рухи хәзинәләр тәшкил итә. Дини берләшмәләр, милли-мәдәни оешмалар, Татарстан халыклары ассамблеясе, Бөтендөнья татар конгрессы шушы традицияләрне саклауга зур өлеш кертә.

Дәүләт һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең үсеше дәвам итә. Мәскәү һәм бөтен Русия Патриархы Кириллның Казан Мәрьям Ана иконасы соборын изгеләндерүе быелның мөһим вакыйгасы булды. 5 ел эчендә яңадан торгызылган гыйбадәтханә тарихи гаделлек һәм җәмгыятьнең рухи үсеше тантанасын гәүдәләндерә.

Киләсе елда бөтен ил белән бергә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Без Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга әлеге датаны федераль дәрәҗәдә бәйрәм итү турындагы карары, Премьер-министр урынбасары Марат Шакирҗан улы Хөснуллин рәислегендә оештыру комитеты төзү өчен рәхмәтле. Тантана кысасында бик күп мөһим чаралар узачак. Шуларның берсе – Казанда Җәмигъ мәчете комплексын төзи башлау. Юбилей датасын лаеклы билгеләп үтү татар халкының рухи-мәдәни мирасын һәм милли үзенчәлеген саклауга зур өлеш кертер дип ышанам.

Киләсе елның җәендә Казан шәһәрендә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясен уздыру дөнья җәмәгатьчелегенең республикабыз казанышларын һәм Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең ЮНЕСКОның Игелекле ихтыяр илчесе буларак әһәмиятле ролен тануын раслый.

Минтимер Шәрипович, бик зур рәхмәт Сезгә!

Бөтенроссия халык санын алу, һичшиксез, гаять мөһим вакыйга булачак. Җәмәгатьчелек белән берлектә дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары алдында халык санын алуны уңышлы уздыру һәм мәгълүмати-аңлату эшләрен оештыру өчен барлык тиешле шартларны тудыру бурычы тора.

Халык фикере

VIII чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлау елның төп иҗтимагый-сәяси вакыйгасы булды. Зур конкурентлык шартларында кешеләрнең тормыш шартларын яхшырту мәсьәләләре буенча җанлы фикер алышу барды. Сайлау нәтиҗәләрен мин хакимият органнарына ышаныч белдерү һәм аларның хезмәтен хуплау, социаль-икътисади үзгәртеп корулар курсын дәвам иттерергә хокук бирү дип кабул итәм. Сайлаучыларның күпчелеге зур тәҗрибәле һәм тормышны белгән, абруйлы һәм тирән белемле кешеләр өчен тавыш бирде. Илебез парламентында Татарстаннан 15 депутат эшләячәк. Бу – үз эшенең остасы булган шәхесләрдән оешкан көчле команда һәм, кайсы сәяси партия вәкиле булуына карамастан, аларның эшчәнлеге федераль дәрәҗәдә республика мәнфәгатьләрен кайгыртуга юнәлтелгән булырга тиеш.
Сайлау барышында татарстанлылардан актуаль мәсьәләләргә кагылышлы бик күп теләк-тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр килде. Аларны хәл итү дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары эшенең төп максаты булырга тиеш. Хөкүмәткә һәм муниципаль берәмлекләр башлыкларына тиешле эшне оештыруны йөклим.

Гражданнарның ышаныч белдерүе, аларның республика үсеше программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыруда катнашуы иҗтимагый үсешкә көчле этәргеч бирә. Иҗтимагый берләшмәләрнең, граждан җәмгыяте институтларының дәүләт идарәсе өлкәсендә карарлар кабул итүгә һәм аларны тормышка ашыру процессына йогынтысы арта бара. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эшчәнлеге халык фикерен ачыклауның нәтиҗәле ысулы булып тора. Безгә әлеге этапта министрлыклар, ведомстволар һәм муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары мөмкинлекләреннән нәтиҗәлерәк файдаланырга, уңышлы эш тәҗрибәсен халыкка киңрәк таратырга кирәк.

Волонтерлар һәм коммерциячел булмаган оешмалар ролен аерып билгеләп үтәсем килә. Татарстан, үзенең иреклеләр хәрәкәтен үстерүнең ресурс үзәге статусын раслап, өченче ел рәттән «Игелекле эшләр төбәге» дигән исемгә лаек булды. Быел әлеге хәрәкәткә 66 мең кеше кушылды. Залда «Ярдәм янәшә!» республика хәрәкәтендә катнашучылар утыра.

Сезгә һәм барлык волонтерларга олы рәхмәтемне җиткерәм!

Граждан җәмгыяте институты буларак, массакүләм мәгълүмат чаралары зур әһәмияткә ия. Мәгълүмати киңлектә радикаль һәм тискәре процессларга каршы тору, төгәл булмаган һәм ялган хәбәрләрне фаш итү кебек мәсьәләләр бик җентекле игътибар сорый. Әлеге нисбәттән, үзенең һөнәри осталыгы һәм гражданлык позициясе нигезендә редакция сәясәтенә йогынты ясый алырдай журналистларыбызның роле бик мөһим булуын аерып билгеләп китәм. «Татмедиа» агентлыгы республиканың Журналистлар берлеге белән әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә тагын да активрак эшләргә тиеш.

Республиканың чит ил партнерлары, Россия төбәкләре белән сәүдә-икътисади, инвестиция, фәнни-техник, мәгърифәти һәм мәдәни элемтәләре – Татарстан үсешенең әһәмиятле факторы. Ислам дөньясы илләре, Көнбатыш дәүләтләре төбәкләре, шулай ук БДБ илләре белән күптөрле тармаклар буенча хезмәттәшлекне киләчәктә дә үстерү зарур. Традицион рәвештә Татарстанда уздырыла торган киң колачлы халыкара һәм бөтенроссия форумнары һәм бәйгеләре мөмкинлекләреннән тагын да киңрәк файдаланырга кирәк. Алар бөтенроссия һәм халыкара мәйданда безнең эшчәнлегебезне киңәйтүгә хезмәт итәргә, татарстанлыларның тормыш дәрәҗәсен яхшыртуга этәргеч бирергә тиеш.

2022 – Татарстанда Цифрлаштыру елы

Дөнья зур тизлектә үзгәреш кичерә, киң мәйданда цифрлы технологияләргә күчеш бара. Әлеге үзгәрешләр һәр кешегә, һәр гаиләгә, һәр һөнәргә, һәр оешмага һәм предприятиегә, икътисадның һәм социаль өлкәнең барлык тармакларына да кагыла. Республикада әлеге юнәлештә бик күп эшләр башкарылды һәм алар дәвам итә. Татарстанда дөньякүләм дәрәҗәдәге ИТ-үзәкләр һәм мәгариф оешмалары булдырылды, электрон сервислар актив рәвештә кулланыла башлады, зур ИТ-компанияләр уңышлы үсеп килә. Бүгенге көндә комплекслы платформа карарларын эшләү һәм бүленгән ситуация үзәкләрен үстерү эше алып барыла. Коммуникацияләрдән, инфраструктурадан һәм хезмәт күрсәтүләр һәм белешмәләрдән файдалану өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә кирәк. Казан шәһәре үзәгендә ИТ-квартал төзү әлеге юнәлештә тагын бер әһәмиятле адым булачак.

Тагын бер кат басым ясап әйтәм, цифрлаштыру – үзмаксат түгел. Бу, беренче чиратта, гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту, аларның мул тормышын тәэмин итү, керемен арттыру, шулай ук бизнесның конкурентлыкка сәләтен үстерү мөмкинлеге бирә торган бер чара. Алга таба да «цифр»га күчүне дәвам иттерү өчен безгә тагын да катлаулырак мәсьәләләрне хәл итәргә туры киләчәк. Бу исә – мәгариф системасы һәм кадрлар әзерләү өлкәсе өчен генә түгел, барлык башка тармаклар өчен дә җитди сынау. Чөнки безгә гадәти уй һәм карашлардан, калыплашкан фикерләрдән баш тартырга, тамырдан үзгәрергә, яңа белемнәр үзләштерергә һәм башкаларны да үзебезгә ияртергә кирәк булачак.

ИТ-технологияләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуда мөһим ролен исәпкә алып, киләсе ел республикада Цифрлаштыру елы дип игълан ителә.

Хөрмәтле депутатлар! Кадерле ватандашлар! «Адым-адым – юл булыр, тамчы-тамчы – күл булыр», – ди халкыбыз. Нәкъ шулай, бары тик алга атлап, без бөтен планнарны тормышка ашыра алырбыз дип ышанам. Иң мөһиме – бу юлдан бергәләп барырга, үзгәрешләрдән курыкмаска!

Без бергә! Безнең көч – бердәмлектә!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме бишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме бишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык Юлламасы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 8 октябре, № 1139-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүдәге мөһим казанышлары, актив иҗтимагый һәм хәйриячелек эшчәнлеге өчен «Казанның 3 номерлы икмәк заводы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Кафаров** Җәвидин Абделнатиф улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Зәй шикәре» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте әйдәүче агрономы **Әхмәтҗанов** Мөнәвир Закир улы; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Лазарев** Валерий Иванович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ТАИФ компанияләре төркеме коллективы, элекке СССР эчке эшләр министры урынбасары, ТАССР эчке эшләр министры, эчке хезмәт генерал-лейтенанты

Николай Иванович ДЕМИДОВның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Бөтен гомерен Ватанга хезмәт итүгә багышлаган зирәк һәм талантлы җитәкче арабыздан мәңгегә китте. Николай Иванович Татарстан һәм бөтен ил халкының иминлеген тәэмин итүгә үзеннән бәһаләп бетергесез өлеш кертте. Ул меңнәрчә кешенең күңелендә көчле, гадел, мәрхәмәтле һәм кешелекле шәхес буларак уелып калды.
Без бу югалтуга бик тетрәндек. Николай Ивановичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

АКСЕНОВА Валентина Николаевна

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Премьер-министры секретариатының җаваплы дежурные Рыгалев Дмитрий Николаевичның авыр кайгысын уртаклаша.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Килә көзләр, яңа көзләр.
Юыла иске эзләр.
Юеш асфальтта кабына
Һаман шул таныш йөзләр.

Мөмкин икән сүнгән утта
Җанны мең кат җылыту!
Тынган бураннарда йөрү!
Юк икән ул оныту!

Югалмый икән күңелнең
Иң олы хәзинәсе –
Балачак истәлекләре,
Яшьлегең хатирәсе.

Рәфикъ ЮНЫС

Мәктәп – изге урын

Кайтаваз

«Ватаным Татарстан» газетасында басылган «Мәктәп: дусмы, дошманмы?» язмасы хәзерге көннең кискен һәм дә бик кирәкле соравын күтәргән. Киң фикерләр белән язылган мәгърифәтле автор Сәрия Мифтахова җавабын кабат-кабат укыдым. Бик үтемле кирәкле киңәшләр тупланган, рәхмәт!

Мин – сугыш елы укучысы. Балтач районы Кенәбаш авылында колхозчы гаиләсендә туганмын. Авылның башлангыч мәктәбендә икенче сыйныфны тәмамлап, өчкә күчкән җәйдә фашистлар сугыш башлады. Укытучыларыма гомер буе чиксез рәхмәтле. Ул елларда авылда да ашарга юк, эшләп үстергән икмәк фронтка китә... Укытучылар өчен тагын да авыр. Китап-дәфтәр юк, иске китап тапсак, юл арасына язабыз; ручканы кош каурыеннан әмәллибез; язу карасын әбиләр салам ягып өй җылыткан мич корымыннан ясап бирәләр (утын юк, бердән, аның корымы суда җебеми икән), аны пыяла савытларда саклап кулланабыз. Башлангыч белемне алгач, өйдән 3–4 чакрым ераклыктагы Түбән Кенә җидееллык мәктәбенә йөреп укыдык. Мәктәпкә кадәр бара алмаучылар бар иде шул... Тагын да шул укытучылар (аларның да ашарларына юк) укучыларын эзләп өйгә киләләр иде.

Ә мин инде 5–6 яшемнән укытучы булырга хыялланам...

Булдым! Шөкер, VII сыйныфны тәмамлаган елны сугыш бетте – җиңдек! Еллар авыр, шулай да укый-укый укытучы булдым; 41 ел төрле сыйныфларда математика укытып, хәзер мин лаеклы ялда! Әмма сугыштан соңгы авыр елларда мәктәптә укытып арымадым, әле дә хыялымда мәктәп тормышы белән яшим!

Әти-әниемә (әти Мәскәүне саклаганда сул аягын билдән үк калдырып кайтты, гаиләдә 8 бала үстек) белем-тәрбия һәм тормыш тәҗрибәсе биргән укытучыларыма, рухи байлыкта үстергән әбиләремә чиксез рәхмәтле мин.

Сүз башым бит бүгенге мәктәп турында иде. Әйе, мәктәп – изге урын! Ышанмаган очракта, әйдәгез, азрак уйланыйк, мәктәпләр һәм бичара укытучылар юк дип уйлыйк. Әти-әни үзләренең «как хатие» белән эш итә, ди. Тормыш-яшәешебез кая кадәр, нинди юл белән дәвам итәр? Без кем булыр, кемнәрне әзерләр идек? Бу сорауларга җавап табып та булмый. Ә мәктәптә бара торган белем-тәрбия эшенә изге ният белән карарга һәм шулай кабул итәргә дә кирәк.

Мәктәпне «тәҗрибә куяны» итмәсәк иде! Югарыдагы җитәкчеләр укытучыларны язма хисап мәшәкатьләреннән коткарсыннар иде. Укытучы хезмәте күп еллар үткәч, укучылары эшли башлагач кына күренә. Ягъни укучы җәмгыятькә кирәкле зат булуын раслаганнан соң гына укытучының дөрес юнәлеш бирүе ачыклана.

Мәдинә ЗЫЯТДИНОВА.
Балтач районы Карадуган авылы

Син җитмисең җанга, әти...

Әтием Гарәфетдин исән булса, аңа 16 октябрьдә 100 яшь тулган булыр иде. Бакыйлыкка күчүенә шактый еллар узса да, җанга барыбер әти җитми. Заманча карашлы, гаилә җанлы кеше иде ул. Без, биш балага, әниегез – алтын, дип әйтә иде. Беркайчан да хурламады, аны кадерле итеп күрсәтте.

Әти белән әни арасында мәхәббәт Арча районының Үрнәк техникумында укыганда ук кабынган. Әни – Сарман, әти – Арча районыннан. Авыл хуҗалыгы юнәлеше буенча белем алганда, юллары икегә аерылган. 1941 елда әтине – Саратовка хәрби очучылар мәктәбенә, әнием Нурлыходаны Тәтеш техникумына җибәрәләр. Ул фронтка азык-төлек җибәреп тора. «Нурлыхода, мине көт, сугыштан кайткач, сиңа өйләнермен», – дип вәгъдә бирә. 1942 елда сугышка кереп, 785 нче полкка 36 нчы очкыч дивизиясенә авиамеханик итеп билгеләнә. I Украина фронтына очкычларны җибәреп торалар. Бу эшне күбрәк төнлә башкаралар. Әти шундый авыр елларда да әнине онытмый, хатлары килеп тора. Яңа ел белән котлап язган открыткасын әле дә саклыйбыз. Сугыштан 1946 елда Польшадан кайта. Биргән вәгъдәсен үти. Әнине эзләп, Сарман районының Хуҗи авылына бара. Тик әни әтинең туган якларына – Арча районының Наласа авылына кайта алмый. Ни өчен дигәндә, әни ятим калган ике сеңлесен ташлап китми. Әти исә төп йортта энесе булгач, аңа ышанып китә Сарманга. Энекәшенә яңа йорт төзергә булыша.

Әти әнигә өйләнеп, бик матур гомер кичерде. Әтиебез 71 яшьтә вафат булгач, әнигә 20 ел пар канатсыз яшәргә туры килде. Әти безгә сугыш еллары турында беркайчан да ачылып сөйләмәде. Ул 1985 елда Дан ордены белән бүләкләнде.

Әти – баш агроном, әни агроном булып эшләде. Теләнче-Тамак дигән авылга йә ат, йә машина белән эшкә йөрделәр. Иртән чыгып китә, кич кенә кайта иделәр. Язгы чәчү вакытында кайсы басуга нәрсә утыртасын әти әйтеп бирә. Үсентеләр утыртып, сортларны сыный. Орлыкларны районлаштыруда да аның өлеше зур. Тора-бара гаиләбез белән Теләнче-Тамакка күчендек. Авылда беренчеләрдән булып яшелчә бакчасы ясадык. Бездән күреп, башка авылдашлар да алмагачын, чиясен, башкасын утырта башлады. Умарта тоттык, мин әтигә бал аертырга булыша идем.

Беренче балага Роберт дип исем кушалар. Әти белән әнинең абыйны академик Тимирязев кебек күрәсе килгән. Абый бик булдыклы: аэрочана ясап шаккатырган иде. Ул бүген академик, Уфада нефть

институтында укыта. Мин Казанда табиб булып эшлим. Башка туганнарым да тормышта лаеклы урыннарын тапты. Әти-әни балалар белемле булсын дип тырышты.

Әти искитмәле кеше иде. Беркайчан да байлыкка кызыкмады, башкаларга ярдәм итәргә тырышты. Балаларга һәрвакыт игътибары җитте аның. Безне урманга алып барып, табигать белән таныштыра, үсемлекләр турында сөйли иде. Бүләккә өстәл уеннары бүләк итәргә ярата иде. Монысы кичләрне бергәләп, күңелле уздырыр өчен. Сүгеп түгел, матур гамәлләре белән, үз үрнәгендә тәрбияләде ул. Мондый әтиләр бүген күбрәк булсын иде.

Суфия ШӘРӘФИЕВА, табибә.
Казан

КОТЛЫЙБЫЗ!

Раиф Фәйзрахман улы Гыйззәтуллинга – 80 яшь!

Кадерле әтиебез! Сине олы бәйрәмең – 80 яшь тулу белән тәбрик итәбез. Сиңа киләчәктә дә исәнлек-саулык, әниебез Нәҗибә белән тигезлектә, бәхетле тормышта яшәвеңне телибез. Йөзеңнән елмаю китмәсен!

Син илебез өчен гаять дәрәҗәдә дәһшәтле елда, туган илебезгә фашист гаскәрләре бәреп кергән 1941 елда Әгерҗе районы Барҗы-Омга авылында тугансың. Әтиең Фәйзрахман сугышның беренче көннәреннән үк фронтка киткән, Мәскәү асты сугышларында катнашкан һәм 1942 елның гыйнварында һәлак булган. Аңа нибары 24 яшь булган. Сез авылда сугыш афәтенең бөтен авырлыгын тоеп яшәгәнсез. Әниең Фәтиха сезне – Рифат абыең белән сине һәм авыру әбине тәрбияләгән. Сез исән калгансыз!

Хөрмәтле әтиебез! Сине Татарстан Республикасында яхшы беләләр. Чөнки син Буа, Балык Бистәсе районнарында эшләдең. Тырышлыгыңны, белемле һәм тәрбияле булуыңны күреп, Татарстан партия өлкә комитетына эшкә чакырганнар. Оештыру бүлегендә шактый еллар хезмәт куйгансың. Хезмәт чорында республикабызның барлык районнары белән элемтәдә булып, иңгә-иң торып эшләгәнсең.

Озак еллар Дәүләт Советында эшләвең синең биографияңне тагын да ныграк бизәгән. Син зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, теләсә нинди йөкне тарта, яшь кадрларга булыша торган җаваплы хезмәткәр булуың белән анда да абруй казангансың. Шуңа күрә дә сине хөрмәт итәләр, олылыйлар. Хезмәтләрең өчен Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең Мактау грамотасына лаек булгансың.

Кадерле әтиебез! Безнең өчен иң кадерлесе – синең сау-сәламәт булып, безгә файдалы киңәшләр биреп торуың, безне яратып яшәвең. Без сине чиксез яратабыз, синең белән горурланабыз! Туган көнең котлы булсын!

Балаларың: улың Айрат, кызың Гөлнара, киленең Гөлнара, оныкларың Алисә, Саидә. Безнең теләкләргә әниебез Нәҗибә дә кушыла

Роберт Андреев: *«Көй шигырьне укыганда ук туа»*

Казанда хәрби ветераннар җырчы, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай бүләге иясе Роберт Андреевның иҗат кичәсен үткәрделәр. Барлык халык яратып тыңлаган «Мин яратам сине, Татарстан!» җырының көй авторы белән очрашырга төрле милләт вәкилләре килгән иде. Кичәдә композиторның тормыш иптәше Мәдинә ханым да катнашты.

Роберт Андреевның 80гә якын җыры бар. Аларны җырчылар Салават, Зөһрә Шәрифуллина, яшьләр дә яратып башкара. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган «Шаулый урман», Клара Булатованың «Кызара инде миләшләр», «Яшьлекне сагыну», «Су буенда кыяк үлән», Җәүдәт Дәрзаманнның «Ышан бары йөрәк авазына» язылган җырлары һәркемнең күңел кылларын тибрәтә. «Көй ул шигырьләрне укыганда ук туа», – ди композитор.

Роберт Андреев Сарман районының Баткак авылында туып үсә. Әтисе Егор абый – оста тимерче, әнисе Александра мал табибы була. Гаиләдә дүртенче бала – Робертның музыкаль сәләтен күреп, аңа 6 яшендә тальян алып бирәләр. Роберт 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Әлмәт шәһәренә китә. Анда техникумга укырга кереп, төзелеш белгечлеге ала.

Туасы көйләре җанында тибрәлә Робертның. Җырмоң сәнгатен тагын да якынрак белер өчен Роберт Андреев Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын читтән торып тәмамлый. Тырыш, сәләтле оештыручы күңеленә ошаган шигырьләргә көйләр яза башлый.

Композитор һаман да иҗат итә. Аның йомшак тавышы, үзенә хас моңы күңелләрне били. Үзләренең балалары, оныкларына гына түгел, миллионлаган җыр сөючеләргә укытучы алар.

Равилә МӨБАРӘКШИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кече яшьтәгеләрне дини берләшмәләргә җәлеп итү, шулай ук кече яшьтәгеләрне, аларның ихтыярына каршы килеп һәм ата-аналарының яисә аларны алмаштыручы затларның ризалыгыннан башка, дингә өйрәтү тыела.»;

б) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяда:

а) 2 пунктның дүртенче абзацында «федераль законга» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктта «берләшмәләр әгъзаларының» сүзләрен «берләшмәләрдә катнашучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Дин белеме бирү оешмалары чит ил мәгариф оешмаларында (үзәкләрендә) дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программалары буенча белем алган дини оешмалар дин әһелләренә һәм дини персоналын тәшкил иткән затларга аттестация үткәрә, алар өчен өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыра.»;

4) 9 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1^1 пункт өстәргә:

«1^1. Түбәндәгеләр дини төркем җитәкчесе (анда катнашучы) була алмый:

Россия Федерациясендә булуы (яшәве) хупланмау турында карар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат;

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль закон) 6 статьясындагы 2 пункты нигезендә исемлеккә кертелгән зат;

үз көченә кергән суд карарында гамәлләрендә экстремистлык сыйфатлары булу билгеләнгән зат;

террорчылыкны финанслауга каршы тору функцияләрен гамәлгә ашыручы ведомствоара координация органы тарафыннан «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законның 7^4 статьясы нигезендә акчаларыннан яисә башка мөлкәтеннән файдалануын туктатып тору (туктату) турында карар чыгарылган физик зат, мондый карар юкка чыгарылганга кадәр.»;

б) 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дини төркем дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле органга соңгы тапкыр хәбәр иткән көннән алып елына кимендә бер мәртәбә «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген дәвам итү турында хәбәрнамә бирә.»;

5) 10 статьяда:

а) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр дини оешмаларның үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керү, аннан чыгу хокукы, шулай ук аларның үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керү, аннан чыгу һәм (яисә) аннан чыгарылу нигезләре һәм тәртибе алар структурага кергән үзәкләштерелгән дини оешма уставында билгеләнгән булса һәм аның эчке билгеләүләренә туры килсә, дини оешмалар үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керергә, аннан чыгарга хокуклы була яисә үзәкләштерелгән дини оешма структурасыннан чыгарыла ала.

Үзәкләштерелгән дини оешманың уставында, аның эчке билгеләүләренә нигезләнеп, дини оешмаларның алар структурага кергән үзәкләштерелгән дини оешмадан чыгуына һәм (яисә) чыгарылуына тыю каралырга мөмкин.»;

б) 5 пунктта «учреждение яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «учреждение» сүзен «оешма» сүзенә алмаштырырга;

в) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кайсы диннеке булуы турында белешмәләр шулай ук дини оешмалар тарафыннан гамәлгә куелган (аларда катнашучылар булган) юридик затларның исемнәрендә күрсәтелергә мөмкин. Башка юридик затлар, оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән юридик затлардан тыш, кайсы диннеке булуы турында белешмәләрне үз исемнәренә кертергә хокуксыз. Оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән юридик затлар, тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың язма ризалыгына нигезләнеп, кайсы диннеке булуы турында белешмәләрне үз исемнәренә кертергә хокуклы.»;

6) 11 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «, әгъзасы» сүзен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законның 6 статьясындагы 2 пункты нигезендә исемлеккә кертелгән зат;»;

7) 12 статьяның 2 пунктында:

а) икенче абзацта «караса, аның да исеме» сүзләрен «һәм (яисә) чит ил дини оешмасына караган очракта аларның исемнәре» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «төп рәвешләре» сүзләрен «төрләре» сүзенә алмаштырырга;

8) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3^1 пункт өстәргә:

«3^1. Чит ил мәгариф оешмаларында (үзәкләрендә) дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программалары буенча белем алган һәм Россия Федерациясе территориясендә тәүге тапкыр гыйбадәт кылырга, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрергә, миссионерлык һәм хәлфәлек эшчәнлеген гамәлгә ашырырга керешүче дини оешмаларның дин әһелләре һәм дини персоналы булган затлар Россия Федерациясе территориясендә гыйбадәт кылуны, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрүне, миссионерлык һәм хәлфәлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруны башлар алдыннан «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә теркәлгән һәм дәүләт аккредитациясенә ия булган югары белем бирү төп уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дини белем бирү оешмаларында яисә белем бирү эшчәнлеген дәүләт җайга салуы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган Россия Федерациясенең федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә һөнәри белем алалар һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың идарә итүче органында (үзәгендә) аттестация узалар.»;

9) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3^1 пункт өстәргә:

«3^1. Исемнәрендә кайсы диннеке булуы турында белешмәләр булган юридик затлар, оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән, тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың әлеге Законның 10 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән язма ризалыгын алган юридик затлардан тыш, 2022 елның 1 гыйнварына кадәр үз исемнәрен әлеге Законның 10 статьясындагы 6 пункты таләпләренә туры китерергә тиеш.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2021 ел, 07 октябрь
№ 78-ТРЗ

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru
«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Киңәш

«Баламның сәләтен күреп алдым, тик нишләргә белмим». Бу сорау күп кенә әти-әниләрне борчыйдыр. Без исә бу хакта Гүзәл Сибгатуллинадан сорадык.

– Әгәр балагызда нинди дә булса сәләт барлыгын күреп аласыз икән, аның шул өлкәнең остасы янына алып барыгыз һәм үзегез күзәтегез. Ул кеше балагызның сәләтен үстерә алачакмы? Бу кызыксынуын сүрелдермәсме? Шәхсән мин шулай эшләдем. Музыка укытучылары бик күп, ләкин араларында тиеш булганга гына эшләүчеләр дә байтак. Ә бала барысын да сизә, тоя бит: аның белән бар күңелеңне биреп шөгыльләнергә кирәк.

Моннан тыш, үзегез дә балагызны үсендереп торыгыз. Балалар чәчкәләр кебек бит ул: су сипмәсәң, үсмиләр. Алар безнең ярдәмне тоярга тиеш.

Гүзәл ханым 10 ел Камал театрында хезмәт куя. 2018 елда балалары хакына эштән китә. Баланың сәләте бәрабәренә үз карьераңны корбан итү дөресме? Өч ел узгач, без аның бу турыда фикерен белергә булдык.

– Мәсьәләнең ике ягы бардыр ул. Танылган актриса Юлия Пересильдны (бу атнада беренче киноэкипаж галәмгә күтәрелде, араларында Юлия да бар. – **Ред.**) гына алыйк. Аның да балалары бар бит. Ә ул галәмгә очты! Мондый кайгыны Аллаһ күрсәтмәсен, тик ул аннан кайтмаска да мөмкин бит. Ул кабаттан үз эшенә тулысынча бирелгәнлеген күрсәтте. Әлбәттә, мондый кешеләргә карап сокланам мин! Үзем дә театрны яратам, кечкенә чакта да зур сәхнәдә чыгыш ясарга хыяллана идем. Үзебезнең Камал театрын да сагынам.

Ләкин мин башка якны сайладым. Беренчедән, Арслан белән Әскәрнең дәү әниләре үз тормышлары белән яшәргә тиеш – аларны борчыйсым килми. Икенчедән, мин няняларга ышанмыйм. Үземне тулысынча балаларыма багышлыйсым килә. Алар бит шулкадәр тиз үсәләр! Ярар, театрда эшлим, тамашачыларым бар, ди. Иртәдән төнгә кадәр шунда. Аннан арып кайтам. Балаларыма нәрсәдер биреп калырга түгел, аларны күрергә дә өлгермим бит алай. Хәлим абый Җәләй һәрвакыт: «Театр да, тамашачы да беркая качмас – гаиләңне онытма», – ди торган иде. Шуңа күрә мин һич кенә дә үкенмим.

Гүзәл Сибгатуллинаның улларына көн саен әйтә торган алты җөмләсе

- **Мин сине шундый яратам!**
- **Син акыллы!**
- **Син көчле!**
- **Син сәламәт!**
- **Синең кебекләр башка юк!**
- **Син иң яхшысы!**

Бу – кызык!

Ә СИҢА НИНДИ ТӨС ОШЫЙ?

Алсу төсләргә мөкиббән киткән кешеләр бар. Кемдер соры, кара төсләргә өстенлек бирә. Баксаң, төскә карап, кеше турында күп нәрсә белеп була икән!

- **Кызыл** – кыю, тиз кабынып китүчән, аралашучан кешеләр төсе.
- **Сары** – кызыксынучан, зыялы, тыныч кешеләр төсе.
- **Ал** – тормыш төсе.
- **Яшел** – табигать, яз төсе.
- **Зәңгәр** – тыйнаклык төсе.
- **Шәмәхә** – хисле, нәзакәтле кешеләр үз иткән төс.
- **Соры** – бар гамәлләрен уйлап, шикләнебрәк эшли торган кешеләр төсе.

АРСЛАН СИБГАТУЛЛИН:
«Футболчы булырга телим!»

Нәни героебызны Татарстанда гына түгел, Россиядә дә яхшы беләләр. Кайчандыр Тукайның «Туган тел» шигырен сөйләп һәм «Священная война» җырын башкарып танылган Арслан СИБГАТУЛЛИНның хәзер өйгә дә кайтып кергәне юк диярлек. Россиянең танылган актерлары белән бер сериалда төшәргә дә өлгерә, спорт турында да онытмый. Йә, калганын үзе сөйләр.

:: Арслан, син бит әле мәктәп укучысы гына. Мәктәптә күбрәк нинди билгеләр аласың, гомумән, укырга вакытың каламы?
– Мәктәптә мин «дүртле» һәм «бишле» билгеләренә генә укыйм. Аеруча математика фәне җиңел бирелә. Әдәбиятны да үз итәм. Әйе, укырга вакыт кала. Башка кызыксынуларымның укуга зыян салуын теләмим, шуңа күрә тырышам.

:: Ә ял вакытын ничек уздырасың?
– Минем тагын бер яраткан шөгылем бар бит әле. Ул да булса – футбол. Үскәч, футболчы булырга телим! Буш вакытым чыгуга, туп тибәргә яратам. Урамга чыгам, табигатьтә йөрим. Иң шәп ял – саф һавада. Минем бит әле энекәшем дә бар. Кайвакытта, урамга чыкмый гына, Әскәр белән туп тибәбез. Ул да шәп уйный, ләкин мине куып тотарга җитезлеге җитеп бетми әле.
Арсланның әнисе Гүзәл, сүзгә кушылып:
– Ай, аларның туп тибүләре! Өйдә! Башта ачулана идем, хәзер инде, тешне кысып булса да, рөхсәт итәм.

:: Әскәрне яратасыңмы, Арслан?
– Бик! Ул гел минем янымда йөри, ярдәм итә, көч биреп тора. Минем белән бергә шигырьләр өйрәнә.

:: Шигырьләр, дигәннән. Беренче шигыреңне ничә яшьтә укыдың, хәтерлисеңме?
– Миңа ул вакытта ике яшь булган. Әнием миңа һәрвакыт Александр Пушкин әсәрләрен укый иде. Хәзер ул минем яраткан шагыйрем! Мин әнине тыңлап, отып барганмын. Ә видеога төшергән беренче әсәрем – Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре. Ул видеода миңа өч яшь.
Гүзәл ханым:
– Ул шигырьне без Мәскәүнең Кызыл мәйданында төшергән идек. Очраклы гына. Планшетның ике процент кына зарядкасы калып бара иде. «Улым, йә төшерергә җитешәбез, йә юк», – дим Арсланга. Шигырьнең соңгы сүзе яңгырауга, планшет сүнде. Мин, гомумән, язмышка ышанам. Монда да, язмыш булган икән, дидем.

:: Арслан, син шигырьләр укыганда нәрсә турында уйлыйсың?
– Укыган чакта мин шигырьнең эченә үк кереп китәм, шуңа күрә берни турында да уйламыйм. Сәхнәгә чыгар алдыннан әнием: «150 процентка, чын күңелдән укырга тырыш», – ди. Шуңа да мин бөтен игътибарымны, күңелем һәм йөрәгемне шигырьгә багышлыйм.

:: Син бит әле шәп җырлыйсың да. Хәзер инде сәхнәгә чыгарга куркып тору юктыр?
– Юк, борчылмаска тырышам. Җырлаганда да чын күңелдән җырлыйм.

:: Безнең укучыларга «Клиника счастья» сериалын төшерү процессы турында да сөйлә әле. Авыр булмадымы?
– Авыр булмады. Киресенчә, бик кызык иде. Бигрәк тә, грим ясаган мизгелләр. Сериалда төшүче актерларның барысы белән дә тиз дуслаштык. Алар бик гади икән. Әле мин Аняга (актриса Анна Антонова. – **Ред.**) кызыл башлыгымны да бүләк итеп калдырдым. Әле дә кия ул аны!
Гүзәл ханым:
– Безне рольгә билгеләгәч, бик сөендек. Съемкаларга аз гына вакыт калып барганда, Арслан кулын сындырды. Ничек борчылганны белсәгез! Беренчедән, кулы өчен, икенчедән, сериал өчен. Курка-курка гына шалтыраттык. Иң кызыгы – безгә «ярар» диделәр. Һәм сериалның сценариен үзгәрттеләр. Шаккаттык! «Арслан бу рольгә бик яхшы туры килә, ул, һичшиксез, сериалда уйнарга тиеш», – диделәр.

Арслан Сибгатуллин турында белешмә

- Ул Казанның 181 нче номерлы мәктәбендә 2 нче сыйныфта белем ала.
- Беренче шигырен ике яшьлек чагында өйрәнә.
- 2017 елда Максим Галкин алып бара торган «Лучше всех» тапшыруында катнаша. Шул ук елны Андрей Малахов алып барган «Пусть говорят» тапшыруында кунак булып кайта.
- Арслан дзюдо белән дүртенче ел шөгыльләнә.
- Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында баручы «Сөембикә» операсында Үтәмеш ролен башкара.
- Арслан шулай ук күптән түгел Россиядә төшерелгән «Клиника счастья» сериалында да Тимофей ролен башкара.
- Кумиры – футболчы Неймар.

ГҮЗӘЛ СИБГАТУЛЛИНА:
«Балага канат куя белергә кирәк»

Ул – ике улының да сәләтләрен күреп, аларны ничек тә үстерергә омтылучы әни. Шул ук вакытта башка балаларның да сәләтләрен ачарга булышучы укытучы. Арслан белән Әскәрнең яраткан әниләре Гүзәл СИБГАТУЛЛИНА турында сүзебез.

:: Арслан, футболчы булам, ди...
– Ул дөньяга килүгә үк, минем күңелемә бер хыял кереп урнашты. Ни өчендер Арслан зур кеше булыр сыман тоела иде миңа. Аны тәүге тапкыр күкрәгемә куйган мизгелдә бер акушерканың телефоннан сөйләшкәнен ишеттем. «Нет у нас никаких звезд!» – диде ул. Шунда, ник булмасын, менә мин актриса бит, дип уйлаганым хәтердә. Ләкин палатадагы «йолдыз» мин түгел, кечкенә Арслан булган икән бит! Хәзер дә минем аны зур сәхнәләрдә күрәсем килә. Ничек кенә булса да, улымның киләчәге якты булуына ышанам.

Футболга килгәндә, әтисе аңа: «Синнән футболчы чыкмас, улым. Бик сәләтле уенчы булсаң да, Россиядә футбол юк бит», – ди. Ләкин тормыш бит бу! Бәлки аңа Европада танылган футбол клубыннан шалтыратырлар да: «Безнең командага нәкъ синдәйләр кирәк» , – дип әйтерләр. Арсланга шулай дип әйткәч, «Мин бит инглиз телен белмим», – ди балакай. Ә без мәктәптәге дәресләргә өстәмә итеп инглиз теленнән онлайн дәресләр дә алабыз. Шуңа күрә мин аңа гел: «Иң мөһиме – максатың булсын. Менә бит, инглиз телен өйрәнәбез, димәк, шул максатка таба әкрен генә атлыйбыз. Хыялланырга курыкма», – дим. Бу сүзләрем чынга ашмаска да мөмкин, ләкин алар балага канат куя. Һәм, нинди генә һөнәрне сайласа да, мин аңа бары тик бәхет кенә телим.

:: Балаларның кәефе гел бер төрле булмый. Арсланның да, киреләнеп, сәхнәгә чыгасым килми, дигән чаклары буламы?
– Әгәр ул үз материалын начар белсә, сәхнәгә чыгарга теләми. Башка вакытта рәхәтләнеп чыга. Мисал өчен генә әйтәм: Арслан биш яшеннән бирле «Сөембикә» операсында уйный. Бер мәлне режиссер ярдәмчесе Арсланга: «Бу сезонны уйнап бетергәч, синең урынга Әскәрне алырбыз инде», – ди. Шундый кайгырды, белсәгез! «Минем әле уйныйсым килә» – бар белгәне шул. Ягъни ул һәр чыгышын күңелен биреп, теләп башкармаса, болай дип әйтмәс иде.

:: Сүз тыңламаган чаклары да буладыр?
– Әлбәттә. Ләкин безнең Арслан йомшак, аның белән килешергә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Арслан белән дуслармы сез? Уртак серләрегез бармы?
– Бик яхшы дуслар! Без бит күп вакытыбызны бергә уздырабыз, шуңа да бер-беребезне ярты сүздән түгел, ярты сулыштан, караштан аңлый башладык. Арабызда ниндидер гадәти булмаган бәйләнеш бар. Мин аңа киңәшләр биргәндә дә чын дусларча сөйләшергә тырышам.

:: Кечкенә улыгыз Әскәр холкы, кызыксынулары белән абыйсына охшаганмы?
– Ул бөтенләй башка, һәм шул ук вакытта алар охшаган да. Әскәр музыка белән шөгыльләнә, фортепианода уйный. Киләсе елга музыка мәктәбенә бирергә ниятләп торабыз. Аннан соң ул рәсем ясарга ярата. Бер тотынса, бүлмәдәге бөтен идән рәсем белән тула. Аның рәсемнәре дә үзенчәлекле, ул дөньяга башка күзлектән карый кебек. Шуңа да без аны «Макетлау» түгәрәгенә бирдек. Сәләтен үстерергә иде.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ВИДЕОСЫ VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Автор – Әскәр Сибгатуллин

Башыңны эшләт



Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 347

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+